


Түбән Кама муниципаль районы башкарма комитетының “Мәктәпкәчә мәгариф идарәсе” муниципаль учреждениесе каршында оештырылган координацион советы утырышында расланды

**Авторлар:**
*Г.М.Хузягалиева* - Түбән Кама шәһәре, 25 нче балалар бакчасының югары категорияле өлкән тәрбиячесе, РСФСР халык мәгарифе отличнигы.
*Г.И. Фасахова* - Түбән Кама шәһәре, 25 нче балалар бакчасының беренче категорияле тәрбиячесе.

**Рецензентлар:**
*З.М.Зарипова* - Яр Чаллы шәһәре өзлексез белем бирү институтының мәктәпкәчә яшьтәге белем бирү лабораториясенең доценты, педагогия фәннәре кандидаты.
*В.С.Казыйханов* - Русия мәктәпләренең атказанган укытучысы, К.Насыйри исемендәге бүләк иясе.
*Н.Г.Гарипова* - Түбән Кама муниципаль районы башкарма комитеты “Мәктәпкәчә мәгариф идарәсе” тәрбия, белем бирү бүлеге мөдиренең милли эшләр буенча урынбасары, югары категорияле җитәкче.

# Бакча утыртмый, алма булмый

*Методик кулланма*

Балалар бакчаларында эшләүче педагогларга, ата-аналарга, педучилище студентларына мәктәпкәчә яшьтәге балаларга хезмәт тәрбиясе бирү буенча методик кулланма.

## КЕРЕШ СҮЗ

Кешенең шәхес булып формалашуында хезмәт тәрбиясенең әһәмияте зур. Хезмәт итеп яшәү – халкыбызның төп халәте. Милләтебезнең төп сыйфатлары, пакълеге, әхлакый сафлыгы, гаделлеге, кешелеклелеге, сабырлыгы, тырышлыгы – барысы да хезмәт даирәсендә күренә.

Хезмәт тәрбиясе акыл, әхлак, зәвык, физик тәрбия төрләрен үстерүгә нигез булып тора. Бары тик хезмәт сөючәнлек, тырышлык кына алга куелган максатларны тормышка ашырырга ярдәм итә. Авыр хезмәт ныклык, түземлек сорый, күп вакыт таләп итә. Авырлыкның җиңелүен, максатка ирешүне тою кешегә чиксез рухи канәгатьлек бирә. Бу шатлыкка хезмәт яратучы кешеләр генә ирешә ала.

Бигрәк тә халык тәҗрибәсе тырыш хезмәт күнекмәләре, киң һәм күпкырлы алымнар, ысуллар җыелмасы аша балаларда хезмәткә, хезмәт кешесенә хөрмәт тәрбияли.

Хезмәт сөйгән кеше генә әхлаклы, акыллы, физик яктан сәламәт, туган иленә ихтирамлы, өлкәннәргә игътибарлы, әдәпле була ала. Халык педагогикасына нигезләнеп, балаларда шул сыйфатларны тәрбияләү, киләчәктә җәмгыятьтә үз урыннарын табарга, үзләре яраткан һөнәр сайларга, бүгенге фәнни алгарыш чорында тормышта югалып калмаска кечкенәдән өйрәтү, барлык халыкларда да эш сөюче кешеләрнең югары бәяләнүен, хезмәтне ярату үз вакыты белән җимешләрен бирүен балаларга төшендерү - тәрбиячеләрнең төп бурычы.

Методик кулланмада беренче кечкенәләр төркеменнән башлап, мәктәпкә хәзерлек төркеменә кадәр, балаларның яшь үзенчәлекләрен искә алып, программа таләпләрен һәм куелган бурычларны үтәү максатыннан, һәр төр хезмәткә өйрәтүнең перспектив планнары, алган белемнәрне тикшерү һәм балалар белән индивидуаль эшне оештыру өчен диагностика үрнәкләре, уеннар, һәр төр хезмәтне башкарырга өйрәтү өчен әзер шөгыль конспектлары, физминуткалар, матур әдәбият әсәрләренең хезмәткә кагылышлы картотекасы, хезмәткә өйрәтү өчен кирәк булган халык авыз иҗаты, һәр төр хезмәт өчен кирәк булган эш коралларының, инструментларның, инвентарьләрнең исемлеге бирелгән.

Татар халык авыз иҗатын, балалар фольклорын һәм танылган татар шагыйрьләре әсәрләрен, ял минутларын, бармаклар өчен күнегүләрне куллану балаларда күтәренке кәеф, эшне нәтиҗәле башкарырга теләк уята,

баланың сөйләмен баета, хәтерләрен яңарта, туган телгә, туган якка, табигатькә сакчыл караш, ярату хисләре тәрбияли.

Методик кулланма тәрбиячеләргә, ата-аналарга, педучилище студентларына хезмәт тәрбиясе бирүдә, төрле хезмәт төрләрен оештыруда, балаларда хезмәткә мәхәббәт тәрбияләүдә, аның шәхси тормышыбыз өчен әһәмиятен аңлатуда, төрле профессияләр белән таныштыруда, дөрес һөнәр сайлауда, иҗади хезмәт белән кызыксыну уятуда, хезмәт итүнең кирәклеген төшендерүдә үз максатын үтәр дип уйлыйм.

Зарипова Зифа Мирхатовна:
Яр Чаллы шәһәре өзлексез белем бирү
институтының мәктәпкәчә яшьтәге
белем бирү лабораториясенең доценты,
педагогия фәннәре кандидаты

04.2008

## МЕТОДИК РЕКОМЕНДАЦИЯЛӘР

1 нче кечкенәләр төркемендә программа буенча түбәндәге хезмәт төрләре кулланыла: үз-үзеңә хезмәт күрсәтү, хуҗалык-көнкүреш хезмәте, өлкәннәр хезмәте белән таныштыру.

Төп максат: балаларны үз-үзләренә хезмәт күрсәтергә - киенергә һәм чишенергә өйрәтү. Педагог, максатына ирешер өчен, дидактик курчак белән эш итә. Курчак үрнәгендә программа таләп иткән бурычларны барлык балаларның үтәвенә ирешә.

Икенче алым булып бу яшьтә бизәнү почмагы тора (уголок ряжения). Балалар төрле костюмнар киеп үз-үзләренә хезмәт күрсәтергә өйрәнәләр.

Өченчедән махсус методик әсбаплар ясарга, дидактик уеннар, мөмкин кадәр күбрәк халык авыз иҗатын кулланырга.

***Диагностика***

| *Бурычлар* | *Культура-гигиена күнекмәләре* | | | | | | *Гади хезмәт күнекмәләре* | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Юыну, сөлгене куллана белү | | Салфетка, кульяулык куллану, чәч тарау күнекмәләре булу | | Ашау күнекмәләре булу | | Киенә, чишенә белүләре | | Уенчыкларны җыя белүләре | | Тышкы кыяфәтен тәртиптә тота белүләре | | Йомыш үти белүләре | |
| Ф.И. | Б | А | Б | А | Б | А | Б | А | Б | А | Б | А | Б | А |
| | | | | | | | | | | | | | | |

*Шартлы билгеләр:*

- бик яхшы (кызыл төстә);
- яхшы (зәңгәр төстә);
- уртача (яшел төстә)
- түбән (соры төстә)

Б- ел башы, А – ел ахыры.

## ПЕРСПЕКТИВ ПЛАН

| *Айлар* | *Үз-үзеңә хезмәт күрсәтү* | *Хуҗалык-көнкүреш хезмәте* | *Өлкәннәр хезмәте белән таныштыру* |
|---|---|---|---|
| Сентябрь. Октябрь. Ноябрь. | Киенергә һәм чишенергә өйрәтү. | Йомышлар кушу: уенчыкны алып бир, китапны өстәлгә куй, урындыкны куй, һ.б. | Кече тәрбияченең хезмәте белән таныштыру. |
| Декабрь. Январь. Февраль. | Шәхси әйберләр (кульяулык, сөлге) белән эш итәргә өйрәтү. | Өс һәм аяк киемен дөрес кияргә, салган киемне пөхтә итеп җыеп куярга өйрәтүне дәвам итү. | Табиб хезмәте белән таныштыру. |
| Март. Апрель. Май. | Чәчми-түкми ашарга өйрәтү. | Төркем бүлмәсен җыештырырга өйрәтү. | Шофер хезмәте белән таныштыра башлау. |
| Июнь. Июль. Август. | Алган күнекмәләрне ныгыту. | Мәйданчыкны, төркем бүлмәсен җыйганда, тәрбияченең кушканын үтәргә гадәтләндерү. | Алган күнекмәләрне ныгыту. |

## *САЛКЫН САФ ҺАВА, ЙОМШАК КАР ЯВА*

### Үз-үзеңә хезмәт күрсәтү. Урамга чыгарга җыену

***Программа эчтәлеге:*** балаларны билгеле бер эзлеклелектә киенергә өйрәтү, үз-үзеңә хезмәт күрсәтү, пөхтәлек, чисталык күнекмәләре бирү.

***Материал:*** ел фасылына туры китереп киендерелгән дидактик курчак.

***Алдан эшләнгән эш:*** киемнәрнең исемнәрен өйрәнү, кая кияргә кирәклеген аңлату.

***Барышы:*** төркем бүлмәсендә әңгәмә. Балалар бүген безгә Алсу (дидактик курчак) кунакка килгән, үзе белән сезне дә урамга чыгарга чакыра. (Алсу белән һәр бала да исәнләшә, хәлләрен сорашалар). Урамда салкын, сезгә дә Алсу кебек киенергә кирәк була.

Алсу киемнәрен күрсәтеп ничек киенергә кирәклеген өйрәтә. Балалар кабатлыйлар.

Шигырь уку.

Алгы бүлмәдә Алсу балаларга шкафтан киемнәрен: колготки, носки, чалбар, кофта алырга кирәклеген әйтә.

Балалар Алсуга иң беренче колготки киеп күрсәтәләр, аннан носки, чалбар, кофта, ә тәрбияче һәм аның ярдәмчесе төзәтә, булыша. Ничек булса да һәр баланың иң беренче колготкиларын киюләренә ирешергә.

Соңнан башлык киелә, куртка, шарф һәм итек.

Алсу балаларны мактый, бергәләп чыгып китәләр.

## Өлкәннәр хезмәте (табиб) белән таныштыру

***Программа эчтәлеге:*** балаларны хезмәт ияләре һәм алар хезмәтенә бәйле эш күнекмәләре белән таныштыру; хезмәт кешесенә карата кайгыртучанлык хисләре, ягымлы караш, мәхәббәт тәрбияләү; батырлык, кыюлыкны үстерү.

***Материал:*** табиб хезмәтенә туры китереп киендерелгән курчак, дәвалау җиһазлары, уенчык куян.

***Алдагы эш:*** табиб киеменә киендерелгән курчакны карау, эш коралларын өйрәнү, К.Чуковскийның “Доктор Айболит” әкиятен уку.

***Сүзлек:*** табиб, авыру, мамык, бинт, дару.

***Методлар һәм алымнар:*** күрсәтмәлелек, практик метод, нәфис сүз, күрсәтү, аңлату, индивидуаль эш.

***Барышы:*** төркемгә колагы ертылган куян керә.

*Куян:* Ай! Авырта, бик авырта.

*Тәрбияче:* Назлыкай, нәрсә булды сиңа?

*Куян:* Колагым бик авырта. Бер усал малай минем колагымны тартты.

*Тәрбияче:* Балалар, ничек ярдәм итик икән Назлыкайга? Әйдәгез, Доктор Айболитны чакырыйк. (Телефоннан шалтыраталар). Доктор Айболит, безнең Назлыкайның колагы бик авырта. Ярдәм итмәссеңме икән? (Табиб киеменә киендерелгән курчак керә). Балалар, Айболит – табиб. Ул авыруларны дәвалый. Өстенә ак халат кигән, кулында сумкасы бар. Сумкасында нәрсәләр бар икән? (Мамык, бинт, дару, кайчы).

*Бер бала шигырь укый:*

Куянымның бер колагын, белмим, кайсы өзгәндер?
Бик тә авырткандыр аңа, белмим, ничек түзгәндер?
Табиб аны дәвалар, колагын тегеп куяр,
Куяным тагын уйнар, сикергәләп тә куяр.

*(Айболит куянны дәвалый: колагына дару сөртә, бинт белән бәйләп куя).*

*Тәрбияче:* Балалар, Айболит Назлыкайны ничек дәвалады? (Колагын текте, дару сөртте, бәйләп куйды). Назлыкайны кем дәвалады? Колагына нәрсә сөртте? Даруны нәрсә белән сөртте? Нәрсә белән бәйләп куйды?

*Назлыкай:* Рәхмәт сиңа, Айболит. Колагым хәзер бер дә авыртмый. (Назлыкай китә). Балалар Айболитка рәхмәт әйтәләр, саубуллашалар.

*Айболит:* Берәр җирегез авыртса, мин сезгә ярдәм итәрмен. (Айболит китә).

(Башка шөгыльләрдә балалар үзләре Айболит булып уйныйлар)

## *КУНАК КӨТӘБЕЗ*

### Хуҗалык-көнкүреш хезмәте

***Программа эчтәлеге:*** балаларны гади эш күнекмәләренә өйрәтү, тәрбияче кушкан йомышны үтәү теләге уяту, хезмәтне нәтиҗәле башкаруга омтылыш тәрбияләү.

***Материал:*** уенчыклар, чүпрәкләр, таслар.

***Алдан эшләнгән эш:*** тәрбиячене҃ хезмәтен күзәтү, әңгәмә үткәрү.

***Методлар, алымнар:*** практик метод, аңлату, күрсәтү, уен.

Сүзлек өстендә эш: киштә, тәртип, пөхтә, кунак, чиста, чайкыйм, күз кысу.

***Барышы:***

- Балалар, безгә бүген кунакка песи килә. Ул бик тә чисталык ярата. Аның өендә бөтен нәрсә тәртиптә икән: уенчыклары киштәдә тора, китапларын тартмага салган. Әйдәгез әле без дә ул килүгә төркемебезне тәртипкә китерик.
- Менә бу киштәдә безнең уенчыклар тора. Мин аларны хәзер таста сабын, чүпрәк белән юам, чиста суда чайкыйм. Ә Алинә аларны кибәргә куярга ярдәм итә. Илнур китапларны матур, пөхтә итеп тартмага сала. Сылу курчакларны, машиналарны киштәгә тезә. Кунакка песи килә.
- Исәнме песи Мияубикә. Рәхим ит, түргә уз. Син килүгә без төркемебезне җыеп куйдык. Сиңа сөт әзерләдек. Менә хәзер Миләүшә сиңа сөт салып бирер. Шигырь дә сөйләр.

*Мияубикә*

*Мәрзия Фәйзуллина.*

Мияубикәгә сөт бирәм, ул эчә леп-леп итеп,
Сәгать теленә охшаган мыекларын селкетеп.

Балалар бик тырыштылар. Аларның синең белән уйныйсылары да килә.

*“Песием-песием” уены.*

Балалар кулларын песигә сузалар һәм такмаклыйлар:
Песи, песи, пес итәр, ана песи сөт эчәр.
Ана песи сөт эчкәндә, ата песи күз кысар
Ал дигәндә алмасаң, лап итәр дә шап итәр!

“Лап итәр” дигәндә, балалар тизрәк кулларын яшерәләр.

Балалар белән уйнагач, песи, яхшы итеп төркем бүлмәсен җыйганнары өчен, аларны мактый. Мәкаль әйтә: “Ялкаулык – хурлык, тырышлык – зурлык”. Мәгънәсен аңлата.

## МЕТОДИК РЕКОМЕНДАЦИЯЛӘР

2 нче кечкенәләр төркемендә программа буенча түбәндәге хезмәт төрләре кулланыла: үз-үзеңә хезмәт күрсәтү, хуҗалык-көнкүреш хезмәте, өлкәннәр хезмәте белән таныштыру, табигатьтәге хезмәт.

Бу яшьтә дә төп максат булып балаларны үз-үзләренә хезмәт күрсәтергә өйрәтү тора.

Алымнар: яхшы үрнәк, театр, уеннар, мактау, халык авыз иҗаты киң кулланыла.

Алдагы төркемнәрдә хезмәт итәргә өйрәтү өчен алшартлар тудырыла, дежур булырга өйрәтелә башлый.

***Диагностика***

| *Бурычлар* | *Хуҗалык-көнкүреш хезмәте* | | | | | | | | *Табигатьтәге хезмәт* | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | *Йомыш үтәү* | | | | | | *Дежур тору* | | | | | |
| | Шөгыльләр өчен | | Уенчыкларны җыю | | Мәйданчыкны җыештыру | | Тәрбияче ярдәмчесенә булышу | | Табигать почмагында эш | | Балалар мәйданчыгында хезмәт | |
| Ф.И. | Б | А | Б | А | Б | А | Б | А | Б | А | Б | А |
| | | | | | | | | | | | | |

*Шартлы билгеләр:*

- бик яхшы (кызыл төстә);
- яхшы (зәңгәр төстә);
- уртача (яшел төстә)
- түбән (соры төстә)

Б- ел башы, А – ел ахыры.

## ПЕРСПЕКТИВ ПЛАН

| *Айлар* | *Үз-үзеңә хезмәт күрсәтү* | *Хуҗалык-көнкүреш хезмәте* | *Өлкәннәр хезмәте белән таныштыру* | *Табигатьтәге хезмәт* |
|---|---|---|---|---|
| Сентябрь Октябрь. Ноябрь. | Киенергә һәм чишенергә өйрәтү. | Мәйданчыкны, төркем бүлмәсен даими рәвештә җыештыруда катнаштыру. | Кече тәрбияче. Табиб. Шәфкать туташы. | Өлкәннәр бу лышлыгы белән яшелчәләр җыярга, бүлмә гөлләренә су сибәргә өйрәтү. |
| Декабрь. Январь. Февраль. | Шәхси әйберләр (кулъяулык, сөлге) белән эш итәргә өйрәтү. | Өс һәм аяк киемен дөрес кияргә, сал ган киемне пөхтә итеп җыеп куярга өйрәтүне дәвам итү. | Табиб. Шәфкать туташы. Аш пешерүче | Бүлмә гөлләре яфракларының тузанын сөртү. |
| Март. Апрель. Май. | Чәчми-түкми ашарга өйрәтү. | Төркем бүлмәсен, җыештыру. Ашханә буенча дежур булырга өйрәтү | Шофер. | Суган утыртырга өйрәтү. |
| Июнь. Июль. Август. | Алган күнекмәләрне ныгыту. | Мәйданчыкны, төркем бүлмә-сен җыйганда, тәрбиянең кушканын үтәргә гадәтләндерү. | Алган белемнәрне, күнекмәләрне ныгыту. | Чәчәкләр үстерергә, түтәлдәге үсемлекләргә су сибәргә өйрәтү. |

**Сөйләм үстерү шөгыле.**
**Кече тәрбияче хезмәте белән таныштыру.**

***Максат:***

- Балаларда хезмәткә карата уңай мөнәсәбәт, хезмәт итү теләге тәрбияләү.
- Өлкәннәргә ярдәм итү теләге булдыру.
- Өлкәннәр хезмәте белән кызыксыну һәм аңа карата хөрмәт тәрбияләү, рәхмәтне матур итеп әйтә белергә өйрәтү

***Барышы:***

Балаларны тәрбияче ярдәмчесе белән таныштыру. Аның исемен әйтергә өйрәтү. Тәрбияче ярдәмчесенең башкарган эшен күзәтү. Ул савыт-сабаны юа, киштәгә матур итеп тезә, балалар ашагач, өстәлләрне, урындыкларны сөртә, идәннәрне, тәрәзәләрне, ишекләрне, стеналарны юа. Балалар турында кайгырта. Тәрбияче ярдәмчесе юганнан соң, бөтен җир чиста, балаларга уйнарга рәхәт була, бүлмә яктырып китә. Тәрбияче балаларга тәрбияче ярдәмчесенә булышырга, өстәл артында пөхтә итеп ашарга, өстәлгә түкмәскә, ризыкны коймаска, идәнне чүпләмәскә, тәрәзәләрне кул белән тотмаска, пычратмаска кирәклеген, аңа һәрвакыт булышырга, чисталыкны сакларга ярдәм итәргә кирәклеген аңлата.

Тәрбияче ярдәмчесе балалар тәрбияләүдә дә булыша: шөгыльләр үткәргәндә, урамга чыкканда, шуңа күрә балалар аңа бик рәхмәтле. Ул кушканны һәрвакыт үтәү, кулдан килгәнчә ярдәм итү теләге тудыру.

*Шигырь уку.*

*“Әнигә булышам”.*

*Газиз Нәбиуллин.*

Бик зур үстем инде мин, әнигә булышам.
Үз ботинкамны үзем кияргә тырышам.
Башка төрле эштә дә файдам бар әнигә.
Уйнап кайткач, пальтомны үзем эләм чөйгә.
Әниемнең эше күп: бәйли миңа оек.
Бүген бөтен уенчыкны үзем куйдым җыеп.

Бу шигырьдәге бала кебек без дә зурларга булыша алабыз. Эш яратырга кирәк, шул вакытта сезне дә яратырлар.

## *ТӘМЛЕ КУЛЛЫ КЕШЕЛӘР*

### Өлкәннәр хезмәте белән таныштыру

***Прграмма эчтәлеге:*** балаларны аш пешерүче хезмәте белән таныштыру; өлкәннәр хезмәтенә карата җылы караш тәрбияләү; ризыкны әрәм итмичә ашап бетерү теләген уяту.

***Материал:*** аш пешерүчегә туры китереп киендерелгән курчак, аш пешерү өчен савыт-саба, яшелчәләр, малай киемендәге курчак.

***Алдагы эш:*** ашханәгә экскурсиягә бару, пешекче хезмәте турында шигырьләр уку.

***Сүзлек:*** аш пешерүче, угыч, салат, яшелчә.

Методлар, алымнар: уен, аңлату, күрсәтү, практик метод, әдәби сүз.

***Барышы:*** (Уенчык курчак керә). Урамда озак уйнадым, тамагым ачты. Нәрсә ашыйм икән?

*Тәрбияче:* Балалар, бу малайга ничек ярдәм итик икән? (Төрле рәсемнәр карыйлар: табиб, аш пешерүче, шофёр). Бу хезмәт ияләренең кайсысы безгә ярдәм итә ала? (Бер бала аш пешерүчене белдергән рәсемне

табып күрсәтә). Балалар, бу аш пешерүче. Ул балаларны тәмле ашлар белән сыйлый. Безнең балалар бакчасында да аш пешерүчеләр эшли. Әйдәгез аны кунакка чакырыйк. (Аш пешерүче килә: башына яулык бәйләгән, өстенә алъяпкыч япкан).

*Аш пешерүче:* Кемнең бик ашыйсы килә? Мин хәзер сиңа тәмле салат ясыйм. (Өстәлдә төрле эш кораллары ята: шприц, руль, мамык, пычак, угыч, тәлинкә, кашык).

*Тәрбияче:* Балалар, пешекчегә нинди эш коралларын сайлап алыйк икән? (Кирәкле әйберләрне сайлап алалар).

*Пешекче:* Кишерне угычта уам, пычак белән кыяр, помидор турыйм, әз генә тоз, май салам, әйбәтләп болгатам. Менә салат әзер дә булды. Рәхим ит, ашап ал.

*Малай:* Рәхмәт сезгә. Бик тәмле булды.

*Тәрбияче:* Балаларны да сыйлагыз инде. (Балалар салат кабып карыйлар. Пешекчегә рәхмәт әйтәләр).

*Бер бала шигырь укый:*

Тәмле ашлар пешерә, ясый котлет, салат та,
“Ашагыз, - ди, тәмле булсын”, безнең пешекче апа.

## *ВИТАМИН ҮСТЕРӘБЕЗ*

### Табигатьтәге хезмәт

***Программа эчтәлеге:*** өлкәннәр булышлыгы белән балаларны суган утыртырга, үсемлекләргә су сибәргә өйрәтү. Балаларда иң гади хезмәт эшчәнлегендә катнашырга омтылыш, эшнең нәтиҗәсенә куану хисләре тәрбияләү, тәрбиячегә ярдәм итү теләген уяту.

Суганның әче булса да, бигрәк тә яшел кыяклысының, файдалы булуын, суык тидергәндә, грипп белән авырганда суган ашарга кирәклеген аңлату.

***Материал:*** утырту өчен тартма, һәр балага суган, лейка, су, таякчык, алъяпкыч.

***Алдан эшләнгән эш:*** рәсемнәр карау, матур әдәбият әсәрләре уку.

***Сүзлек өстендә эш:*** витамин, кыяк, салат.

Методлар, алымнар: практик метод, күрсәтү, аңлату, нәфис сүз, халык авыз иҗаты, проблема кую.

***Барышы.***

Пешекче киеменә киенгән, кәстрүл, чүмеч тоткан курчак керә:

- Мин дусларыма салат ясамакчы идем, минем яшел суганым юк. Балаларга витамин бик тә кирәк, ләкин минем кәстрүлдә зур башлы суганнар гына. Ничек итеп яшел кыяклы суган үстерергә икәнен белмим.

*Тәрбияче:*

- Бер дә борчылмагыз, без сезне яшел кыяклы суган үстерергә өйрәтербез. Балалар сезгә булышырлар.

Тәрбияче алъяпкыч кия. булышырга теләгән балалар да алъяпкыч кияләр. Менә бу тартмада җир, ул яхшылап җылытылган. Хәзер җиргә су сибәргә кирәк. Марат лейка белән су сибә. Таякчык белән хәзер утыртыр өчен урын әзерлибез. Тәрбияче суганны алып, тамырын күрсәтеп, җиргә утыртып күрсәтә.

Балалар барысы да суган утырталар. Тәрбияче суганны җиргә нык итеп батырырга икәнен искәртә, кыенсынган балаларга ярдәм итә. Тагы су сибәләр, тәрбияче суганга көн дә су сибәргә кирәклеген әйтә. Пешекче апага суганның кыягы үскәч, чакырачакларын әйтәләр (курчак китә). Тәрбияче суган турында табышмаклар әйтә:

- Җир астында җирән ат, аның тиресе җиде кат,
  Суярсың да тунарсың, тунаганда еларсың.
- Үскәндә яфрагын ашыйлар, үсеп җиткәч үзен ашыйлар.
- Ормый, сукмый, үзе кешене елата.

Тәрбияче балаларга булышулары өчен рәхмәт әйтә. Шигырь уку.

*“Нәни булышчы”.*

*Мәрзия Фәйзуллина*

Ул әле нәни булса да, һәрбер эштә булыша.
Аңар, нәни булышчым, дип, әнисе исем куша.

Бу шигырьдәге бала кебек, сез дә бүген зурларга булыштыгыз. Нәни булышчылар булдыгыз. Эш яратып үскән балалар турында “Эш сөйгәнне ил сөяр” дип әйтәләр.

## *ЭШ БЕТКӘЧ, УЙНАРГА ЯРЫЙ*

### Үз-үзеңә хезмәт күрсәтү. Урамнан кергәч киемнәрне җыеп кую

***Программа эчтәлеге:*** балаларны билгеле бер эзлеклелектә чишенергә, киемнәрне пөхтә итеп төреп шкафка куярга өйрәтү, үз-үзеңә хезмәт күрсәтү, пөхтәлек, чисталык күнекмәләре бирү, киемнәрнең исемнәрен ныгыту, мөстәкыйльлек тәрбияләү.

***Материал:*** ел фасылына туры китереп киендерелгән дидактик курчак, уенчык шкаф, курчак киемнәре.

***Алдан эшләнгән эш:*** киемнәрнең исемнәрен өйрәнү, кая кияргә кирәклеген аңлату, эзлекле киенүгә игътибарны юнәлтү.

Сүзлек өстендә эш: киштә, өске, аскы, уртада.

Методлар, алымнар: уен, аңлату, күрсәтү, практик метод, әдәби сүз.

***Барышы:***

Тәрбияче (дидактик курчакны күрсәтеп) Алсуның урамнан кергәч киемнәрен матур итеп төреп куймавын әйтә. Аның киемнәре бөгәрләнгән. Уенчык кием шкафыннан курчакның киемнәрен бушаталар. Башлыгын ул аяк киемнәре янына куйган, колготкины төрмәгән, киемнәре аңа үпкәләгәннәр.

Әйдәгез бергәләп шкафны тәртипкә китерик, Алсуны да өйрәтик.

Өске киштәгә яулык, башлыкны куябыз. Уртадагы киштәгә матур итеп төреп кофтаны, колготкины, ыштанны, аскы киштәгә сандаликны, чешкиларны куябыз. Кем Алсуга ярдәм итәр икән? Дамир курчак киемнәрен төреп урнаштыра. Балалар әйтеп торалар.

Дидактик уен “Дөрес әйт”. Өс, аяк, баш киемнәрен аерып магнитлы тактага тезү. Өскә баш, уртага өс, аска аяк киемнәре рәсемнәрен тезү. Киемнәрнең исемнәрен әйтү. Алсу балаларга рәхмәт әйтә.

Балалар Алсуга шигырь укыйлар, башта эшне эшләргә, киемнәрне җыеп куярга, аннан соң гына уйнарга икәнен әйтәләр.

Без инде хәзер зурлар, күп эшли безнең куллар.

Без идән дә юабыз, без керләр дә уабыз.

Гөлләргә су сибәбез.

Тәрбияче балаларны мактый. Эш яратып үсүләрен, акыллы булуларын тели. “Эш беткәч, уйнарга ярый” дигән мәкальнең мәгънәсен аңлата.

## *ТЫРЫШ ХЕЗМӘТ БУШКА КИТМӘС*

### Хуҗалык-көнкүреш хезмәте

***Программа эчтәлеге:*** балаларны шөгыльләр өчен кирәк-ярак әсбапларны тәртиптә тотарга өйрәтү, коллектив өчен тырышып эшләү теләген уяту, бердәмлек, иптәшләре белән тату хезмәт итү күнекмәләре тәрбияләү. Балаларда иң гади хезмәт эшчәнлегендә катнашырга омтылыш тәрбияләү. Өлкәннәр кушкан эшне үтәргә гадәтләндерү. Төсләрне аерырга өйрәтү.

***Материал:*** тартмалар, чүпрәкләр, савыт белән су.

***Алдагы эш:*** сынлы сәнгать почмагына экскурсия ясау, төрле матур рәсемнәр карау.

***Сүзлек:*** капкач, буяу, пөхтә, тартма.

***Методлар, алымнар:*** уен, аңлату, күрсәтү, практик метод, әдәби сүз.

***Барышы:*** Карандаш кунакка килә. Ул иптәшләрен югалтуын әйтә.

- Кая икән алар, сез белмисезме? Минем үземә генә бик күңелсез.

*Тәрбияче:* Балалар, Карандашка ярдәм итик. Синең дусларың менә монда яшиләр. Рәсем почмагын, андагы киштәләрне күрсәтәләр.

*Карандаш:* Ай-ай-ай. Минем дусларым монда таралып, буталып беткәннәр. Кая монда кызыл карандаш, кая монда сары карандаш? (Карандаш бик борчыла).

*Тәрбияче:* Балалар, әйдәгез әле киштәне җыештырыйк, Карандашның дусларын табыйк, аларны матур тартмага салыйк. (Балалар кызыл, сары, яшел, зәңгәр, ак, кара карандашларны аерым тартмаларга салалар).

*Карандаш:* Рәхмәт сезгә, балалар, миңа дусларымны табарга булыштыгыз.

*Тәрбияче:* Әйдәгез Карандашка рәсем ясап бүләк итик. (Салават күпере ясыйлар).

*Карандаш:* Рәхмәт сезгә, мин хәзер дусларымнан беркайчан да аерылмам.

Тәрбияче тырышлыкның бушка китмәвен, һәрвакыт бәхеткә илтүен аңлата.

## МЕТОДИК РЕКОМЕНДАЦИЯЛӘР


Бу яшьтә программа буенча каралган барлык хезмәт төрләре дә кулланыла. Төп игътибар  балаларның башлаган эшләрен тәгәлләүләренә, коллектив белән эшли белүләренә юнәлтелә. Бу яшьтә дә төп хезмәт төре булып үз-үзеңә хезмәт күрсәтү кала.

Балаларны дежур булырга өйрәтү бу яшьтә аеруча мөһим, дөрес күнекмәләр алган балалар, зурлар төркемендә эшне мөстәкыйль башкарачаклар.

***Диагностика***

| ***Бурычлар*** | ***Хуҗалык-көнкүреш хезмәте*** | | | | | | | | | | ***Табигатьтәге хезмәт*** | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Төркем бүлмәсен, уенчыкларны җыю | | Мәйданчыкны җыештыру | | ***Дежур тору*** | | | | | | | | | |
| | | | | | Ашханәдә | | Шөгыльләрдә | | Табигать почмагында | | Яшелчә бакчасында эш | | Балалар мәйданчыгында хезмәт | |
| Ф.И.О. | Б | А | Б | А | Б | А | Б | А | Б | А | Б | А | Б | А |
| | | | | | | | | | | | | | | |

*Шартлы билгеләр:*



- бик яхшы (кызыл төстә);
- яхшы (зәңгәр төстә);
- уртача (яшел төстә);
- түбән (соры төстә)

Б- ел башы, А – ел ахыры.

## ПЕРСПЕКТИВ ПЛАН

| *Айлар* | *Үз-үзеңә хезмәт күрсәтү* | *Хуҗалык-көнкүреш хезмәте* | *Өлкәннәр хезмәте белән таныштыру* | *Табигатьтәге хезмәт* |
|---|---|---|---|---|
| Сентябрь. Октябрь. Ноябрь. | Мөстәкыйль киенә, чишенә белүләрен камилләштерү, киемнәрен пөхтә итеп элеп кую, тәртиптә тоту. | Төркем бүлмәсен, участокны һәрвакыт тәртиптә тоту. | Кече тәрбияче. Табиб, теш табибы. Шәфкать туташы. | Мөстәкыйль рәвештә бүлмә гөлләренә су сибәргә, яфракларның тузанын сөртергә өйрәтү. Үсемлекләрне күчереп утырту эшендә катнаштыру. |
| Декабрь. Январь. Февраль. | Пөхтә булырга өйрәтү. Киемнәрне шкафларга төреп урнаштыру, сак караш тәрбияләү. | Дежурлык бурычларын төгәл башкару ларына ирешү. | Табиб. Шәфкать туташы. Аш пешерүче. | Балаларны кошларга ашату өчен үсемлекләр үстерү, орлык чәчү эшенә тарту. Кышлаучы кошларны ашату. |
| Март. Апрель. Май. | Үз-үзеңә хезмәт күрсәтүдә бер-береңә булышуга зур игътибар бирү. | Коллектив хезмәт белән төркем бүлмәсен җыештыру | Шофер. Хат ташучы. Сатучы | Суган утыртырга өйрәтү. |
| Июнь. Июль. Август. | Алган күнекмәләр не ныгыту. Кечкенә балаларга киенергә, чишенергә булышу. | Мәйданчык ны, төркем бүлмәсен мөстәкыйль җыюларына өйрәтү. | Алган белемнәрне, күнекмәләрне ныгыту. | Яшелчә бакчасында рәт araларына ком, сибү, орлык чәчү, туфракны йомшарту, уңыш җыеп алуда катнаштыру. |

## *ҺӨНӘРЛӘР ТУРЫНДА ӘҢГӘМӘ*

**Тирә-юнь белән таныштыру шөгыле**

***Максат:*** Балаларның һөнәрләр турында белемнәрен ныгыту, әңгәмәгә катнаштыру, җөмләне дөрес төзеп, сорауларга тулы җавап бирүләренә ирешү.

Логик фикерләү сәләтен үстерү. Хатаны күрә белергә, төзәтергә өйрәтү, үзеңнен фикереңне исбатлап күрсәтү, бу һөнәр ияләренең эш кораллары турында белемнәрен ныгыту, гомумиләштерергә, классификацияләргә өйрәтү.

Хыялларында әйбернең бер билгесе буенча башка әйберләр тудырырга өйрәтү, күзаллауларын үстерү. Әйбернең схемасына карап, күзаллауларында образ тудыру, кирәкле элементларны ясап бетерү, әйберләрне өлешләргә бүлеп карарга, образлы фикер йөртергә өйрәтү.

Төрле психик күнегүләр кулланып, балаларда психик процессларны үстерү. Балаларның аңлап, кешеләрнең төрле кичерешләрен (ягымлы, уйчан, усал...) күрсәтә алырга өйрәтү.

***Җиһазлау:*** пешекче, шофер, врачның эш кораллары; эш кораллары төшерелгән таблица; компьютер уены өчен таблица; уен “Нәрсә артык?”, уен “Ясап бетер”, төрле эмоциональ хәлдәге врач рәсемнәре.

***Сүзлек өстендә эш:*** символ, компьютер, һөнәр.

***Барышы:***

*1.Оештыру.* Балалар музыка уйнаганда залга керәләр. Тезелеп басалар. Исәнләшәләр. Тәрбияче кечкенә шигырь сөйли:

Җир йөзендә һөнәрләр күп, алар бит төрле-төрле.
Шул һөнәрләр арасыннан, сайлап алчы син берне.

Җир йөзендә бик күп төрле һөнәрләр бар. Барлык һөнәрләр дә кешеләр өчен кирәк.Сез дә үсеп җиткәч, үзегез яраткан һөнәрләргә ия булырсыз. Балалар, ә сез нинди һөнәрләр беләсез? (Җаваплар). Без бүген сезнең белән һөнәрләр турында сөйләшербез.

*2. Төп өлеш.* Тәрбияче балаларның игътибарын өстәлдәге эш коралларына юнәлтә. Кемнәрнеңдер эш коралларын калдырып китүләрен әйтә. Табышмакларга җавап табып, бу коралларның кемнәрнеке икәнен беләләр.

- Ак халатлы, калфаклы, үзе сабыр, ягымлы.
  Без авырсак терелтә, шифа бирә куллары *(врач).*
- Тәмле ашлар пешерә, безне сыйлый, туйдыра.
  Зур үссеннәр балалар дип, күп көч куя аларга *(пешекче).*
- Иртә, көндез һәм кичен, машинасын кабызып,
  Китә ерак җирләргә, кешеләрне утыртып *(шофер).*


Балалар табышмакларның җавабын тапкач, һөнәр ияләре залга керәләр һәм бергә һөнәрләр иленә сәяхәткә китәләр.

Иң беренче һөнәр ияләренең эш коралларын табып бирәләр. Эш кораллары өстәлдә ята. Тәрбияче эш кораллары ясалган, ләкин капланган таблицаны күрсәтә. Символларны (врач, пешекче, шофер) карап чыгалар. Бу сүзне истә калдыру өчен берничә тапкыр кабатлыйлар.

Һәр символ турысында шушы һөнәр кешеләренең эш кораллары яшерелгән. Тәрбияче эш коралларын каплаган фигураның нәрсәгә охшавы белән дә кызыксына. (Җаваплар: кашык, погремушка, ипи тактасы, таба һ.б.) Чынлыкта ул күз врачы куллана торган лопатка. Бер бала чыгып лопаточканы ала. Эш коралының исемен әйтә, нәрсә өчен кирәклеген аңлата һәм өстәлдән алып врачка бирә.

Тагы ике бала шоферга һәм пешекчегә дә эш коралларын табып бирәләр.

Һөнәр ияләре рәхмәт әйтәләр, "Үз урыныңны тап" уенын бүләк итәләр. Балаларга врач, шофер, пешекче символлары төшерелгән рульләр бирәләр. Музыка уйнаганда балалар зал буйлап төрлечә хәрәкәт итәләр. Музыка туктагач, үзләренең рульләрендәге символларга туры килгән һөнәр кешеләре янына җыелалар. Уен 2-3 тапкыр уйнала. Һөнәр ияләренә шигырьләр укыйлар.





*Шофер булам*

Мин дә әтием шикелле шофер булырга уйлыйм.
Шуның өчен һәрвакыт машина белән уйныйм.
Тизрәк үсеп шофер булсам, нишләргә белер идем
Урамдагы бар баланы утыртып йөрер идем.

*Пешекче*

Тәмле ашлар пешерүче, безне сыйлап торучы,
Зур үссеннәр балалар дип төрле ризык бирүче
Ул пешекче беләбез, аны сөя һәммәбез.

*Врач*

Ак халатлы апалар, бик тә ягымлы алар.
Җылы сүзләре белән дә терелтә безне алар.
Кайсы җирең авырта дип, сөеп тыңлап карыйлар.
Тизрәк терел яме диеп, уколын да казыйлар.

*Җыр: "Һөнәрләр күп".*

*З.Хәйретдинов музыкасы.*
*Х.Халиков сүзләре.*

(Җырдан соң һөнәр кешеләре чыгып китәләр).

Хәзер үзебезнең белемнәребезне компьютерда тикшереп карыйк. Ә кем компьютер турында сөйли ала? Компьютер ул кешегә уйларга, санарга ярдәм итә торган машина. Һәрбер баладан бу сүзне әйттерү. Бүген сезгә компьютер һөнәрләр турында белемнәр бирә.

Балаларның теләге буенча компьютерның бер төймәсенә басабыз. Рәсем (повар, врач, пешекче) килеп чыга. Нинди рәсем килеп чыкса, шул һөнәр кешесенә кирәкле эш коралларын табалар. Уен “Нәрсә артык?” (Һөнәр кешесенә туры килмәгән рәсемне каплыйлар). Дөрес эшләгәндә компьютерда матур көй уйный.

*Физминут “Күрсәт әле, үскәнем”.*

*Уен “Ясап бетер”.* (Ясалып бетмәгән эш коралларын ясап бетерәләр).

*Психогимнастика.* Балаларга картина тәкъдим ителә. Анда врач рәсемнәре. Сезгә бу врачларның кайсысы ошый? (Җаваплар). Көзге янына килеп елмаеп карыйлар.

Ишек шакып повар керә. Пирог бүләк итә.

*Җыр “К нам гости пришли”.*

3.Йомгаклау. Һөнәрләрнең бик күп төрле булуы, һәр хезмәтнең мактаулы булуы әйтелә.

## Табигатьтәге хезмәт.
## Яшелчә бакчасында кишер чәчү

***Программа эчтәлеге:*** балаларны табигатьтә хезмәт итәргә өйрәтү, эшне теләп, күңел биреп башкару, тәрбиячегә ярдәм итү теләген уяту, хезмәткә мәхәббәт тәрбияләү.

***Материал:*** көрәк, тырма, таякчыклар, кишер орлыгы, лейка, чиләк. су.

***Алдан эшләнгән эш:*** колхозчыларның, бакчачыларның язгы эшләре турында әңгәмәләр үткәрү, рәсемнәр карау, матур әдәбият әсәрләре уку.

***Сүзлек өстендә эш:*** чәчү, орлык, үлчәп алу, аралаштыру, сирәкләү, буразна, үсенте.

***Методлар, алымнар:*** практик метод, күрсәтү, аңлату, нәфис сүз, халык авыз иҗаты, проблема кую.

***Барышы.***

Яшелчә бакчасына килү. Түтәл белән танышу. Нинди эшләр башкарылуын санап чыгу: түтәл казылган, тырмаланылган. Нинди эш кораллары кулланылган, күрсәтеп сөйләү.

Табышмак әйтү:

- Утыра бер кыз җир астында, ә чәчләре җир өстендә.

*Тәрбияче:*

*(Кишерне күрсәтеп)* монда ул бер генә. Ә ничек соң көз көне күп итеп кишер җыеп алырга? (проблема куя).

*(Орлыкларны күрсәтә)* орлыкларны чәчкәч, күп итеп кишер үсеп чыга. Менә шушы вак кына орлыкта зур кишер йоклый. Ул уянсын өчен аны җиргә чәчәргә кирәк. Эш бүленә: ике бала таякчыклар белән буразна ясый. буразналар арасы тигез булсын өчен арасын шартлы үлчәм белән үлчибез, аны ике бала башкара. Һәр бала ком белән аралаштырган орлыкларны буразнага сала. Буш ара калдырырга ярамый. Орлыкларны җил очырмасын өчен, аны җир белән каплыйбыз.

Үсемлекләр үссен өчен кояш җылысы, су кирәк. Су тигез сибелсен өчен лейка белән су сибәбез. Өсне, аякны юешләтмичә генә эшлибез.

Суны көн дә сибәргә кирәк. Берничә көннән орлыклар уяныр, үсентеләр кояшка тартылыр. Ә көз җиткәч, без кишерне җыеп алырбыз, ашханәгә кертербез.

Кем белә, кишердән нинди ризыклар пешерәләр? (ашка турыйлар, бөккән пешерәләр, сок ясыйлар, пешермичә дә ашыйлар, ул витаминнар чыганагы, үсәргә булыша, күз күрүен яхшырта).

Тәрбияче хикәя сөйли. “Алсуның куллары”, Заһирә Гомәрова. “Бал бабай”, 119 бит.

## *ЙОМШАК СУ, ЙӨГЕРЕК СУ*

### Үз-үзеңә хезмәт күрсәтү

***Программа эчтәлеге:*** балаларны пөхтәлеккә, тышкы кыяфәтләрен тәртиптә тотарга өйрәтү. Мөстәкыйль юына, сөлгене куллана белүләрен камилләштерү, сөлгене пөхтә итеп элеп кую, тәртиптә тотарга күнектерү.

Үз-үзеңә хезмәт күрсәтүдә бер-береңә булышуга зур игътибар бирү.

Культура-гигиена күнекмәләрен үстерү, юыну предметларына сак караш тәрбияләү.

***Материал:*** сабын, сөлге, сабын савыты.

***Алдан эшләнгән эш:*** К.Чуковскийның “Юынгыч” (“Мойдодыр”) әкиятен уку, әдәплелек, чиста булу турында әңгәмәләр үткәрү.

***Сүзлекне баету:*** микроб, пөхтә, сабынлау, юынгыч.

Методлар, алымнар: уен методы, аңлату, күрсәтү, практик эш, нәфис сүз.

***Барышы:*** төркемгә пычрак киемле, юынмаган малай (курчак) керә, тиз генә табын артына килеп утыра:

- Мин “Юынгыч” әкиятеннән качып сезнең янга кунакка килдем әле. Монда минем дусларым бардыр дип беләм. Сабыннан, мунчаладан, юынгычтан, судан көч-хәл белән качтым.

*Тәрбияче:*

- Юк, юк. Безнең арада андый балалар юк. Тик чисталык сөйсәң генә безнең дустыбыз булырсың. Безнең балалар сине яхшылап юынырга өйрәтерләр, син өйрәнергә, безнең дустыбыз булырга телисеңме?
- Әйе, мин теләмәсәм сезнең дустыгыз була алмыйм бит.

- Балалар, безгә юыну өчен нәрсәләр кирәк? *Табышмаклар әйтү:*
    - Җанлы кебек шуа, качып китәсе килә.
      Ләкин аны нык тотам, кулларымны мин юам *(сабын)*
    - Түгәрәк тә, овал да, шома һәм хуш исле дә.
      Суга салсаң күбекләнә, тәнне бик чиста итә,
      Шул аның бар эше дә *(сабын).*
    - Урамнан кергәч, ваннага барам
      Һәм мин аны үзем белән алам.
      Тәнне юарга, чиста булырга,
      Бар микробларны юк итәргә *(сабын).*
    - Мунча кергәч, юынгач
      Миңа ул кирәк була.
      Аркамны да, кулымны да
      Ул корытып сөртә *(сөлге)*

Тәрбияче матур савытка салынган хуш исле сабынны күрсәтә, барысы да иснәп карыйлар (җиләк исе килә, шома, овал формасында). Әле ул суда күбекләнә белә, бик яхшы сыйфаты бар, зыянлы микробларны юк итә, безнең битләребезне, кулларыбызны чистарта. Малайга юыну тәртибен аңлаталар (юыну бүлмәсенә керәләр). Башта җиңнәрне сызганалар, сабынны алып күбекләндерәбез, кулларны яхшылап ышкыйбыз, су белән чайкыйбыз. Шигырь уку:

*Йомшак су, йөгерек су.*

*Җ.Тәрҗеманов.*

Йомшак су, йөгерек су! Син мине чиста ю!
Бер тап та калмасын, битләрем аллансын,
Кулларым агарсын.
Тешләрем тазарсын... авызым елмайсын,
Колагым тыңласын,
Йомшак су, йөгерек су! Һәммәсен чиста ю!

Инде безгә дустыбыз сөлге кирәк. Аны элгечтән алып, кулларны яхшылап корытабыз һәм сөлгене урынына элеп куябыз. Җиңнәрне төшереп, сәдәпләп куябыз.

Курчакны юындырып, яхшылап сөртәләр.

*Тәрбияче:*

- Менә хәзер син безнең балалар белән дус була аласың. Безнең балалар пөхтә, чиста дусларны яраталар.

## *РӘХМӘТ КЕМГӘ ДӘ РӘХӘТ*

### Хуҗалык-көнкүреш хезмәте

***Программа эчтәлеге:*** балаларда хезмәткә карата уңай мөнәсәбәт, хезмәт итү теләге тәрбияләү, үз өсләренә йөкләнгән шәхси һәм коллектив

эшләрне башкарып чыгарга, башлаган эшне ахырына җиткерергә өйрәтү. Өлкәннәр кушкан эшне үтәргә гадәтләндерү. Өлкәннәр хезмәте белән кызыксыну һәм аңа карата хөрмәт тәрбияләү. Иптәшләренә, өлкәннәргә ярдәм итү теләге булдыру.

***Материал:*** бау, тас, сабын, кер кыстыргычлары.

***Сүзлек өстендә эш:*** чайкау, кер кыстыргычы, бау.

***Алдан эшләнгән эш:*** курчаклар белән уеннар, аларның киемнәренә игътибар бирү, рәсемнәр карау, “Буратино” әкиятен уку, Мальвина белән танышу.

***Методлар, алымнар:*** уен, аңлату, күрсәтү, практик эш.

***Барышы:*** тәрбияче хат укый. Мальвина бик тә курчаклар яратуын, алар белән туган көн бәйрәмен үткәрәсе килүен язган. Һәм төркемдәге курчакларны кунакка чакырган.

Балалар курчакларны бәйрәмгә әзерлиләр. Киемнәрен юалар, курчакларның үзләрен дә коендыралар. Эш өчен ике тас, сабын, бау, кер кыстыргычларын әзерлик. Башта бауны сузып, кыстыргычларны элеп куялар. Таска су салалар. Алинә керләрне сабынлый, Айгөл юа, сыга, аннан Сылуга бирә, Сылу аларны чайкый, Гөлназ белән Тимур бауга эләләр, кыстыргыч белән эләктерәләр. Ни өчен керләрне кыстырып куярга кирәк? Дөрес, төшеп китмәсеннәр, пычранмасыннар өчен.

Ә хәзер курчакларны юындырабыз, чәчләрен тарыйбыз, аяк киемнәрен юып кигертәбез.

Күлмәкләре кипкәч, үтүкләп кидертәбез.

*Мальвина килә (кулында торт).*

- Исәнмесез, дусларым, сез бүген нинди матурлар. Мин мондый чиста, пөхтә дусларны бик тә яратам. Бәйрәмгә рәхим итегез. Балалар курчакларны өстәл артына утырталар. Мальвинага “Ак калач” җырын җырлыйлар.
- Мальвина балаларга дус, тату булганнары, тырышып эшләгәннәре өчен рәхмәт әйтә. “Киңәшле эш таркалмас” дигән мәкальдәгечә, киңәшләшеп эшләргә, бер-береңә ярдәмчел булырга чакыра.

## МЕТОДИК РЕКОМЕНДАЦИЯЛӘР

Бу яшьтә балалар барлык эшләрне дә мөстәкыйль башкаралар, коллектив белән хезмәт итәләр. Тәрбияче башкарылган эшнең сыйфатына зур игътибар бирергә, һәр балага индивидуаль якын килергә тиеш.

Кул эше шөгыльләрендә югары нәтиҗәләргә ирешү максатыннан, түгәрәк эше алып бару яхшы була.

### *Диагностика*

| ***Бурычлар*** | ***Зурлар хезмәте белән таныштыру*** | | | | ***Кул хезмәте*** | | | | ***Хуҗалык-көнкүреш хезмәте*** | | | | | | | | | | ***Табигатьтәге хезмәт*** | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | | | ***Дежур тору*** | | | | | | | | | |
| | Хезмәт төрләре, анын эчтәлеген белүләре | | Төрле һөнәр ияләренең хезмәтен бәяләү | | Кәгазь, картон, тукыма белән эшли белүләре | | Табигать, ташландык материаллар белән эш | | Коллектив хезмәт | | Кушкан эшне үтәү | | Ашханәдә | | Шөгыльләрдә | | Табигать почмагында | | Табигать почмагында эш | | Балалар мәйданчыгында, бакчадагы хезмәт | |
| Ф.И.О | Б | А | Б | А | Б | А | Б | А | Б | А | Б | А | Б | А | Б | А | Б | А | Б | А | Б | А |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

*Шартлы билгеләр:*

- бик яхшы (кызыл төстә);
- яхшы (зәңгәр төстә);
- уртача (яшел төстә)
- түбән (соры төстә)

Б- ел башы, А – ел ахыры.

**ПЕРСПЕКТИВ ПЛАН**

**Конструкцияләү, кул эше (конструирование, ручной труд).**

| ***Атна*** | ***Сентябрь*** | ***Октябрь*** | ***Ноябрь*** |
|---|---|---|---|
| 1 | Төзү материалыннан конструкцияләү «Җиһаз» | Оригами «Бака» | Оригами «Стакан» |
| 2 | Табигый материалдан декоратив панно “Милли орнамент” | Кәгазьдән конструкцияләү «Кәрзин» | Конструктордан «Корабль» |
| 3 | Оригами «Күбәләк» | Табигый материалдан «Ташбака» | Кәгазьдән конструкцияләү «Ике палубалы пароход» |
| 4 | Төзү материалыннан конструкцияләү «Чулман елгасы аша күпер». | Төзү материалыннан ирекле конструкцияләү | Картоннан «Курчакка өстәл һәм урындык ясау» |
| | ***Декабрь*** | ***Январь*** | ***Февраль*** |
| 1 | Төзү материалыннан “Капка” ясау. | Төзү материалыннан ирекле конструкцияләү | Төзү материалыннан “Мәчет” |
| 2 | Кәгазьдән чыршы уенчыклары ясау. | Тукыма белән эш. “Салфетка” | Кәгазьдән кечкенә балалар өчен китапчык ясау. |
| 3 | Кәгазьдән милли орнамент кулланып серле сандык ясау. | Табигый материалдан чыршы ясау | Сәдәф тагарга өйрәнү |
| 4 | Конструктордан “Самолет” ясау. | Кәгазьдән милли орнамент кулланып ковер ясау. | Табигый материалдан “Вертолет” ясау |
| | ***Март*** | ***Апрель*** | ***Май*** |
| 1 | Кәгазьдән “Автобус” ясау. | Тукыма белән эш “Серле капчык” | Чигәргә өйрәнү |
| 2 | Милли орнамент белән кулъяулык чигү | Табигый материалдан коллектив эш | Оригами “Лалә” |
| 3 | Оригами “Балык” | Картоннан курчакка җиһаз ясау. | Ташландык материалдан букет ясау. |
| 4 | Юл билгеләрен кон- | Тукыма һәм | Кәгазьдән ирекле |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | струкцияләү. | поролоннан инә кадагыч ясау. | конструкцияләү. |

## ПЕРСПЕКТИВ ПЛАН

### Үз-үзеңә хезмәт күрсәтү. Хуҗалык-көнкүреш хезмәте

| *Айлар* | *Үз-үзеңә хезмәт күрсәтү* | *Хуҗалык-көнкүреш хезмәте* |
|---|---|---|
| Сентябрь | Киенүдәге тәртипсезлекне бетерү, киемне һәм аяк киемен саклау. | 1.Ашханәдә һәркөнне дежур тору.<br>2.Бакчада яшелчә җыю.<br>3.Һәркөнне мәйданчыкны җыю. |
| Октябрь | Таракны, кульяулыкны куллана, ашаганнан соң авызны чайкый, йокларга ятканда теш чистарта белү | 1.Һәркөнне шөгыльләрдә дежур тору.<br>2.Тузан сөртү (шкаф, киштәләр).<br>3.Төзүчеләр хезмәтен күзәтү. |
| Ноябрь | Дөрес ашау, приборларны ашагач илтеп кую, өстәлне сөртү. | 1.Үз эш урыныңны җыю.<br>2.Курчак керләрен юу.<br>3.Шофер хезмәтен күзәтү. |
| Декабрь | Урын-җирне җәя белү, тузан сөртү, уенчыкларны җыю. | 1.Һәркөнне табигать почмагында дежур тору.<br>2.Җиһазлардан тузан сөртү.<br>3.Юлларга ком сибү.<br>4.Кер юучы һөнәре белән таныштыру. |
| Январь | Кием шкафын тәртиптә тоту. | 1.Йокыдан соң урынны җыю.<br>2.Китапларны ремонтлау.<br>3.Кардан төрле корылмалар ясау.<br>4.Урам җыештыручы һөнәре белән таныштыру. |
| Февраль | Мәйданчыкта юлларны чистарту, тау ясау, киемнәрне киптерү. | 1.Урын-җирне алмаштыруда тәрбияче ярдәмчесенә булышу.<br>2.Уенчыкларны юу.<br>3.Тегүче һөнәре белән таныштыру. |
| Март | Киемне чиста тоту, киемдәге тәртипсезлекне бетерү, иптәшеңә ярдәм итү. | 1.Чиста урын-җир әйберләрен караватларга тарату.<br>2.Киемнәрне прогулкадан соң киптерү.<br>3.Почтага экскурсиягә бару. |
| Апрель | Һәркөнне төркемне җыю, тәртиптә тоту. | 1.Салфеткалар юу.<br>2.Комны казу.<br>3.Веранданы себерү. |
| Май | Пөхтә итеп киенү, чәчне тәртиптә тоту. | 1.Үз урын-җиреңне әзерли белү.<br>2.Урамда уйнау өчен уенчыклар ясау.<br>3.Пешекче хезмәте белән |

| | | |
|---|---|---|
| | | таныштыру. |
| Июнь<br>Июль<br>Август | Алган белемнәрне ныгыту. | 1.Һәркөнне комны казу.<br>2.Һәркөнне уенчыкларны юу.<br>3.Мәйданчыкны тәртиптә тоту.<br>4.Су сибү. |

**ПЕРСПЕКТИВ ПЛАН.**

**Табигатьтә хезмәт. Табигать почмагында хезмәт.**

| ***Айлар*** | ***Табигатьтә хезмәт*** | ***Табигать почмагында хезмәт.*** |
|---|---|---|
| Сентябрь | 1. Бакчада уңыш җыю.<br>2. Түтәлләрне чистарту, казу, георгин, гладиолус суганчаларын казып алып, сакларга кую.<br>3. Өлгергән генә орлыкларны җыю. | 1.Һәркөнне гөлләрне карау, дөрес су сибәргә өйрәтү<br>2.Яшел суган үстерү<br>3.Урамдагы гөлләрне күчереп утырту. |
| Октябрь | 1.Кипкән букет ясау өчен чәчәкләр әзерләү.<br>2.Үз куллары белән уенчыклар ясау өчен табигать материаллары туплау. | 1.Һава торышын календарьдә билгеләп бару.<br>2.Кипкән яфраклардан, орлыклардан картина ясау. |
| Ноябрь | 1.Һәркөнне кошларны ашату өчен җимлекләр элү.<br>2.Агач төпләренә кар өю. | 1.Дежурныйлар календарь тутыралар.<br>2.Көз, көзге эшләр турында рәсемнәр урнаштыру. |
| Декабрь | 1.Һәркөнне мәйданчыкны җыештыру.<br>2.Юлларга ком сибү<br>3.Чыршы бизәү. | 1.Солы чәчү.<br>2.Тәҗрибә ясау, үсемлекләргә үсү өчен җылы һәм якты кирәк.<br>3.Кошларны күзәтү. |
| Январь | 1.Һәркөнне кечкенә төркем балаларын чанада тартып йөрү, мәйданчыкларын кардан чистартырга булышу.<br>2.Тау ясауда катнашу. | 1.Арпа чәчү.<br>2.Суган, сарымсак утырту. |
| Февраль | 1.Кардан крепость ясау. | 1.Кар һәм бозны чагыштыру.<br>2. Кошларны ашату.<br>3.Суган үсешен күзәтү, рәсемен ясау. |

| | | |
|---|---|---|
| Март | 1.Сыерчык оялары элү.<br>2.Мәйданчыкны кардан чистарту. | 1.Бүлмә гөлләре утырту.<br>2.Чәчәк орлыклары утырту. |
| Апрель | 1.Бакчада язгы эшләрдә катнашу. | 1.Беренче язгы чәчәкләрне күзәтү.<br>2.Агач ботакларын суга утырту, үсешен күзәтү. |
| Май | 1.Бакчада су сибү эшендә катнашу.<br>2.Түтәлләргә яшелчәләр утыртуда катнашу (редиска, кишер).<br>3.Беренче язгы чәчәчкләрдән гербарий ясау. | 1.Әкәм-төкәмне күзәтү.<br>2.Урман кошларының рәсемнәрен карау. |
| Июнь<br>Июль<br>Август | 1.Һәркөнне түтәлләргә су сибү, чүпләрен утау.<br>2.Дару үләннәреннән гербарий ясау.<br>3.Укроп чәчү.<br>4.Түтәлләрне казу, чүпләрен җыю.<br>6.Төрле әйберләр (поделка) ясау өчен яфраклар җыю. | 1. Дару үләннәренең рәсемнәрен карау, әһәмиятен аңлату.<br>2.Урамдагы чәчәклеккә яран, кына, юкә гөлләрен күчереп утырту. |

## ***КЕЧЕГӘ ШӘФКАТЬ ИТ, ЗУРЛАРНЫ ХӨРМӘТ ИТ***

### Кул эше шөгыле. Тукыма белән эш. Чәчәк ясау.

***Программа эчтәлеге:***

- Балаларны тукыманың уртасына туры китереп сәдәп тагарга өйрәтү.
- Төен ясау күнекмәләрен ныгыту.
- Эш кораллары белән сак эшләргә кирәклеген искә төшерү.
- Тегүче һөнәре турындагы белемнәрен тирәнәйтү.
- Хезмәт кешеләренә мәхәббәт тәрбияләү.
- Балаларны Хәйрия елы эмблемасы белән таныштыру. Яхшы эшләр эшләргә рухландыру. Кешелеклелек, ярдәмчеллек, изгелек сыйфатлары, нәниләргә карата һәрвакыт кайгыртучанлык хисләре тәрбияләү, аларны рәнҗетмәү.

**Җиһазлау**: магнитофон, аудиокассеталар, курчак.

***Курсәтмә материал:*** Хәйрия елы эмблемасы рәсеме. Әзер чәчәкләр.

***Таратма материал***: һәр балага диаметры 10 см лы түгәрәк яшел төстәге тукыма, сары төстәге сәдәп, тукымадан эшләнгән ак, кызыл, зәңгәр төстәге чәчәкләр, җепле энә, кайчы.

***Сузлек остендә эш:*** Хәйрия елы, изгелек, шәфкатьлелек, алиһә.

***Методик алымнар:*** әңгәмә, сораулар, проблемалы сораулар, уен, практик эш, нәфис сүз, халык авыз иҗатын куллану.

***Алдан эшләнгән эш:*** физминуткалар, мәкальләр өйрәнү, таратма материалларны әзерләү, төен ясарга, сәдәп тагарга өйрәтү.

**Индивидуаль эш:** пассив балалар белән алдан шөгыльгә әзерләнү, кызыксындыру.

**Шөгыльнен структурасы:**

1. Оештыру. Балалар кунакларга карап басалар. Исәнләшәләр. Тәрбияче балаларны "Яхшылык" алиһәсе белән таныштыра. "Яхшылык" иленә кунакка чакыра. (Музыка уйный.)
2. Төп өлеш.
   - Рәсемне күрсәтеп Хәйрия елы турында әңгәмә үткәрү.
   - Тегүче хезмәте белән таныштыру.
   - Эш тәртибен аңлату.
   - Физминутка. Бармакларны әзерләү.
   - Балаларның эшләре. Музыка уйнап тора.
   - Уен "Энә, җеп, төен".
3. Йомгаклау. Тукымадан ясалган чәчәкләрне нәни балаларга бүләк итү.

1. *Оештыру.*

Балалар, бүген безгә кунакка "Яхшылык" алиһәсе килгән. Ул безне үзенең "Яхшылык иле"нә кунакка чакыра. Барабызмы, балалар? (Музыка уйный, балалар күзләрен йомалар, күз ачып йомганчы бу илгә килеп тә җитәләр).

2. *Төп өлеш.*

(Тәрбияче Хәйрия елының рәсемен күрсәтә) Балалар, карагыз әле, кемнең бу рәсемне күргәне бар? Кайда? (Балаларның җаваплары). Ничек уйлыйсыз? Бу илнең исеме ничек икән? (ТАТАРСТАН). Әйе, бу рәсем Хәйрия елының эмблемасы. Ул һәрвакыт яхшы эшләр эшләргә кирәклеген искәртеп тора.

Ә сез нинди яхшылыклар эшли аласыз? Бүген мин сезне ДУСТЫМ белән 1 яхшылык эшләргә өйрәтәсем килә. Әйдәгез, без кечкенә балаларга тукымадан чәчәкләр ясап бүләк итик. Алар бит кечкенәләр, үзләре ясый белмиләр. Бу чәчәкләр ярдәмендә алар төсләрне аерырга, киемнәрендәге төймәләрне эләктерергә, ычкындырырга, нәтиҗәдә яхшы итеп сөйләшергә дә өйрәнерләр.

Эшне башкарып чыгу өчен безгә кораллар кирәк. Хәзер сез табышмаклар тыңлап китәрсез, нәрсә икәнен әйтерсез. (Энә, җеп, кайчы турында). Бу эш кораллары кайсы һөнәр кешесенә кирәк? (Тегүчегә).

Эш кораллары белән ничек эш итәбез, ни өчен?

- Сезнең өстәлләргә яшел төстәге түгәрәк формадагы тукыма – бу чирәм. Сары төстәге сәдәпләрне тукыманың уртасына тагабыз – бу чәчәкнең уртасы. Әзер чәчәкне шушы сәдәпкә эләктереп куябыз.

- Башта энәне тукыманың аскы ягына кадыйбыз. Төен аскы якта кала. Сәдәпне тагып бетергәч, шулай ук, җепне төенләп куябыз. Кайчы белән кисеп алабыз, энәне кадап куябыз.
- Э хәзер ясый башлаганчы бармакларны эшкә әзерлик. Бастык.
- Балаларның эшләре. (Музыка уйный, тәрбияче авырсынган балалар белән индивидуаль эш алып бара).
- Балалар ясап бетергәч, "Яхшылык" алиһәсенә китерәләр. Тәрбияче әзер чәчәкләрне алиһәнең матур тартмасына салырга булыша.

3. *Йомгаклау.* Балалар, сезгә "Яхшылык" илендә ошадымы? Ә хәзер әйдәгез бакчага кайтыйк. Алиһә дә безнең белән кайта. Ул сезне һәрвакыт яхшылык эшләргә өндәп торыр. Алиһә сезнең чәчәкләрегезне бик ошатты. Алар безнең нәниләребезгә дә ошар. Ул сезне бик яратты. Сездән яхшы эшләр көтә һәм үзенең биюен бүләк итә.

Балалар, сез бик тырышып эшләдегез. Минем дэ сезгә бүләгем бар. (Бирә). Эш беткәч уйнарга да ярый. Уен "Энә, җеп, төен".

Ә хәзер кемнәр матур җаваплар бирде, алар белән бүләк тапшырып киләбез.

## ***КАР БӨРТЕГЕ***

### **Кул эше шөгыле. Кәгазь белән эш.**

***Максат:*** балаларны кәгазь белән эшләргә күнектерү; кәгазьне 2,4,8 өлешкә бүлә белүне камилләштерү; логик фикерләүләрен, фантазияләрен үстерү, матурлыкны күрә белергә өйрәтү; табигать белән кызыксынучанлык тәрбияләү.

***Әсбаплар:*** диаметры 15см булган, түгәрәк юка ак кәгазь, кайчы, поднослар.

***Җиһазлау:*** схемалар, үрнәкләр.

***Алдан башкарылган эш:*** табигатькә кагылышлы шигырьләр, хикәяләр, әкиятләр уку; табышмаклар кичәсе үткәрү, оригами алымнарын ныгыту.

***Сүзлек өстендә эш:*** Карбикә, карлар патшалыгы, диагональ, .

***Методлар:*** күрсәтмәлелек, җыр, уен, халык авыз иҗаты.

***Барышы:***

Тәрбияче балаларга табышмак әйтә:

Ак мамык кебек, ялтырый алмаз кебек (кар бөртеге).

Дөрес, кар бөртеге. Ләкин кар бөртегенең гомере бик кыска. Җылы урынга, кулга тисә, ул юк була. Аларның матурлыгы югала. Ә бит кар бөртекләре нинди матур! Алар бер – берсенә бөтенләй охшамаганнар!

Шулай уйланып торганда, Түгәрәк ай киңәш бирде: "Карлар, бозлар патшалыгына сәяхәткә барыгыз", - диде ул. (Балалар юка кәгазьдән тугәрәкләр кисәләр). Тәрбияче кулында "тулган ай":

- Ә Карлар патшалыгына ничек эләгергә соң? “Моның өчен уйланырга, үзеңне әкият илендә кебек хис итәргә кирәк. Менә минем кебек” – диде тулган ай.
- Менә мин хәзер урталай бөкләнәм дә, үземә охшамаган халәткә киләм.

Тәрбияче балалардан сорый:

- Ай нәрсәгә әйләнде, ул нинди предметка охшаган хәзер? (Җаваплар).
- Ә минем гөмбә эшләпәсенә дә, бишеккә дә охшыйсым килми! Менә хәзер мин тагын урталай бөгеләм дә, сез мине бөтенләй дә танымаячаксыз. Шулай диде дә, үзенең почмакларын бергә китереп бөкләнде.
- Хәзер ярты ай нәрсәгә охшады? (Воронкага, колпакка, пирог кисәгенә, веерга...).
- Әйе, сезгә салкын булып киткәндер? Сез чын тылсымчылар икән диде, - пирог кисәге, җилләткәч, өй почмагы.
- Сез Карлар Патшалыгыннан ерак түгел. Тизрәк анда эләгер өчен мин хәзер тагын бер тапкыр урталай бөкләнәм.
- Хәзер инде мин бөтенләй очланып, нечкәреп беттем. Инде мин нәрсәгә охшап калдым? (Боз сөнгесенә, туңдырмага, конуска...)
- Безнең кәгазь кисәгенең туңдырмага әйләнүе булды, Карлар Патшалыгында яшәүчеләр аны төрле яктан чолгап алдылар.

Иң беренче булып Карбикә килде дә кечкенә генә кисәк тешләп алды. Ул туңдырманы бик ярата иде. (Балалар кисеп алалар).

- Минем дә туңдырма ашыйсым килә, - диде Боз малае үзенең очпочмаклы теше белән озын өчпочмак кимереп алды. (Балалар кисеп алалар).
- Кар кызы килде дә, туңдырманы ялап китте, менә мондый ярымтүгәрәк эз калды.
- Карлар, бураннар, салкыннар килде дә, туңдырманы төрле яклардан кимерә башладылар. (Тәрбияче һәм балалар кайчы белән төрле яклардан кисеп алалар).
- Тугәрәк ай безгә тылсым ясады да юкка чыкты. Әйдәгез аны эзлибез, кайда икән ул, аның белән нәрсә булды икән?

Карлар Патшалыгына эләгер өчен, без гел кәгазь битен бөкләп бардык. Хәзер инде төшенер өчен безгә киресен эшләргә кирәк.

Балалар ашыга – ашыга Тылсымчы Айны эзлиләр һәм аның матур кар бөртегенә әйләнгәненә төшенәләр.

Кар бөртеге нинди? (Җиңел, матур, салкын, йомшак)

Балалар уйныйлар: “Кар бөртеге өйгә керде. Өй эчендә очып йөрде. Менә шулай...”

## *БАШЛЫЙ БЕЛСӘҢ, БЕТЕРӘ БЕЛ*

**Хуҗалык-көнкүреш хезмәте. Төркем бүлмәсен җыештыру. Бергәләп эшне (коллективный труд) оештыру.**

***Программа эчтәлеге:***

- Балаларда хезмәткә мәхәббәт тәрбияләү.
- Йөкләнгән эшне җиренә җиткереп башкарырга, эшне ахырына җиткерергә, эш коралларын урыннарына җыеп куярга гадәтләндерү.
- Материал һәм предметларга сак караш тәрбияләү.
- Күмәк эшләрдә башкалар белән беррәттән катнашып, килешеп эшләү теләге, план төзеп эшли белү, тирә-юньдәгеләр өчен кирәкле кеше булу, билгеле бер нәтиҗәләргә ирешү омтылышы тәрбияләү
- Балаларга өлкәннәр хезмәте турында күзаллау бирү, хезмәтнең нәтиҗәсен, аның җәмгыять өчен әһәмиятен күрсәтү.
- Кешеләр хезмәтен җиңеләйтү максатында төрле техникадан файдалану турында белемнәр бирү.

***Җиһазлау:*** таслар, лейка, таякчыклар, алъяпкычлар, чүпрәкләр.

***Барышы:***

- Балалар, бүген атнаның нинди көне? (Җомга). Һәр җомга саен без сезнең белән нинди эш башкарабыз? (Төркем бүлмәсен җыештырабыз).
- Бүген без нәрсәләр эшләячәкбез? (Шкафларның, урындыкларның, өстәлләрнең тузаннарын сөртәчәкбез, уенчыкларны, гөлләрне, төзелеш материалларын, курчакларны, аларның киемнәрен юачакбыз)
- Хезмәт турында нинди мәкальләр беләсез?
  - Сүзең белән эшең бер булсын.
  - Агач җимеше белән, кеше эше белән.
  - Аннан-моннан эшләсәң, яңадан эшләрсең.

Һәр мәкальнең мәгънәсен искә төшерү.

- Ә хәзер, балалар, әйдәгез төркемнәргә бүленик, эшне бүлешеп алыйк.

1. Төркем: Айнур, Айгөл, Наил, Ильяс. Урындыклар юа.
2. Төркем: Алина, Валерия, Динар. Өстәлләр юа.
3. Төркем: Алия, Айгөл, Тимур, Оля чәчәкләр юа.
4. Төркем: Динар, Гөлназ, Элмира, Рөстәм, Илвир шкафтагы тузаннарны сөртә.

*Шигырь уку.*

Минем куллар эшләп торсын,  төркемебез балкып торсын.
Шкафлар, киштәләр чиста булсын, уенчыклар матур тезелсен.
Гөлләр көлеп торсын һәм безгә рәхмәт әйтсен.

Балалар алъяпкычлар кияләр, эш коралларын алалар һәм эшне башлыйлар. Эш барышында мәкальләр әйтү.

Эш беткәч, эш коралларын урынына куялар. Анализ һәм әңгәмә үткәрелә. Балалар үзләренең ничек эшләүләре турында сөйлиләр. Ә

тәрбияче балаларга сораулар биреп, тузан суырткыч турында сөйли. Аларның тагы нинди кешеләрнең хезмәтен җиңеләйтүче эш коралларын белүләре белән кызыксына.

Бердәм (коллектив) хезмәт турында мәкальләр искә төшерелә.

- Күмәк кул тау күтәрә.
- Күмәк эш күңелле эш.

## *ТЫРЫШЛАР ҺӘМ УҢГАННАР*

### *КВН.* Хезмәткә багышланган кичә.

***Максат:***

- Балаларга хезмәт күнекмәләре бирү, кул хезмәте белән шөгыльләнүне дәвам итү. Төрле әсбаплар, эш кораллары белән эшләргә өйрәтү. Хезмәт өчен кирәк-яракны әзерләргә, сайлап алырга өйрәтүне дәвам итү.
- Балаларның иҗади, образлы фикерләү сәләтен үстерү, тирә-юнь турындагы белемнәрен арттыру, логик фикерләргә өйрәтү.
- Эш кораллары белән сак эшләргә өйрәтү, үз эшенә җитди карап, иптәшләренең эшенә куану, хезмәткә, хезмәт кешеләренә хөрмәт тәрбияләү, матурлыкны, эшнең нәтиҗәсен күреп сөенү, башлаган эшне ахырына җиткерү, эшне чиста, пөхтә башкарырга өйрәтү.

***Алдан эшләнгән эш:*** хезмәт, хезмәт иясе, һөнәрләр турында әңгәмәләр үткәрү, кул эше шөгыльләрен үткәрү, хезмәт турында җырлар, шигырьләр, мәкальләр, уеннар, физминуткалар өйрәнү, матур әдәбият әсәрләре уку. “Мин үскәч кем булырмын” дигән темага рәсемнәр ясау. Таратма материалларны әзерләү. Чигәргә, сәдәп тагарга, бәрәңге әрчергә, тегәргә, чүкеч белән кагарга өйрәтү.

***Сүзлек өстендә эш:*** һөнәр, хөрмәт, хезмәт иясе, хурлык.

***Җиһазлау:*** магнитофон, аудиокассеталар. КВН үтәсе залда күргәзмәләр ясау:

- Чигү түгәрәгенә йөрүче балаларның эшләре. Тәрбияче Фасахова Гүзәл Илдус кызы.
- Тәрбиячеләр, балалар, ата-аналарның кул эшләреннән күргәзмә.
- Балалар рәсемнәреннән күргәзмә. “Үскәч мин кем булачакмын?”

Шөгыль өчен кирәкле әсбаплар әзерләү: чигү, сәдәп тагу, бәрәңге әрчү, тегү, чүкеч белән кагу өчен.

***Методик алымнар:*** әңгәмә, сораулар, күрсәтмәлелек, ярышу, мактау, музыка, драматизация, уен, практик эш, нәфис суз куллану.

***Индивидуаль эш:*** пассив балалар белән алдан шөгыльгә әзерләнү, кызыксындыру.

***Шөгыльнең структурасы:***

*1.Кереш.*

Оештыру. Хезмәт турында шигырьләр уку. “Ике ялкау” әкиятен драматизацияләү. Мәкальләрне искә төшерү.

Командаларга бүленү, сәламләү, капитаннар сайлау.

*2.Төп өлеш.*

Командаларга биремнәр:

- “Оригами” алымы белән көймә ясау.
- Төймә тагу.
- Чигү.
- Хәрәкәтле уен.
- Күлмәк өлгесе кисү.
- Агачтан уенчык ясау.
- Музыкаль тәнәфес.
- Бәрәңге әрчү.

*3. Жюри чыгышы. Командалар эшенә бәя бирү.*

*4. Җыр “Зөлфия хезмәт сөя”. (Н.Зарипова музыкасы, Г.Таһирова сүзләре).*

***Барышы**:*

**1.** Марш астында балалар залга керәләр. Ярымтүгәрәк булып басалар.

*Тәрбияче:* без бүген хезмәт бәйрәменә җыелдык. Бүгенге ярышларыбыз, җырларыбыз, шигырьләребез барысы да хезмәткә багышланган. Сезнең уңганлыкны күрергә күпме кунак килгән. Әйдәгез алар белән исәнләшик.

Хезмәт - кешенең яшәү чыганагы. Юкка гына “Хезмәт иясе – хөрмәт иясе” димәгәннәр. Хезмәт кешесе һәрвакыт хөрмәткә лаек. Әгәр сез, балалар, кечкенәдән хезмәт сөйсәгез, кулыгыздан килгән кадәр ата-анагызга, өлкәннәргә ярдәм итсәгез сез тырыш, уңган, хөрмәтле кеше булып үсәрсез. Хезмәт кешесен, эш сөйгән кешене зурлап күпме җырлар, шигырьләр, мәкальләр язган халкыбыз.

*Алсу шигырь сөйли. “Кул арасына керәм”. С.Рәхмәтуллина.*

*Ләйсән. “Әнигә булышам”. Г.Габиди.*

*Әкият карау.* ”Ике ялкау”. Шушы тамаша буенча мәкальләр әйтү:

- Хезмәт төбе – хөрмәт.
- Җәй эшләсәң – кыш ашарсың.
- Эш сөйгәнне ил сөяр.
- Хезмәтнең тире ачы булса да, җимеше татлы.
- Эшләмәгән ашамый.

**2.** Командаларга бүленү.

*Беренче команда:* “Уңганнар”. Девиз: “Без хезмәтне зурлыйбыз, ялкаулыкны хурлыйбыз”. Капитан – Ришат.

*Икенче команда:* “Тырышлар”. Девиз: “Без хезмәтне сөябез, эшчән булып үсәбез”. Капитан – Рәмис.

*Капитаннар ярышы:* кем күбрәк һөнәр исемнәрен белә.

**3.** Ярышлар өстәл артында дәвам итә.

Хәзер, дуслар, көч сынашыйк, батырлар алга чыксын.

Һәр бала КВН да осталыгын, зирәклеген, тапкырлыгын күрсәтсен.

- Кәгазьдән көмә ясау.
- Кем матур итеп чигеп бетерә? (Инә, кайчы белән эшләүне искә төшерү). Лотос чәчәген чигеп бетерү.
- Сәдәп тагу.

*Уен. “Инә, җеп, төен”.*

*Рената шигырь сөйли. “Күлмәк тектем”. Р.Вәлиева.*

*Ришат. “Чүкеч”. Җ.Дәрзаман.*

Ярышлар дәвам итә.

- Кызлар күлмәк өлгесе кисә, малайлар агачтан эшләнгән уенчыкны ясап бетерәләр. Музыкаль тәнәфес. Ришат курайда уйный.
- Бәрәңге әрчү. Кемнәр бәрәңге әрчеми табигый материалдан вертолет ясыйлар.

Жюри нәтиҗә ясый.

*Җыр. “Уңган безнең Зөлфия”. Н.Зарипова музыкасы. Г.Таһирова сүзләре.*

## *ХЕЗМӘТЕНӘ КҮРӘ ХӨРМӘТЕ*

### Табигать почмагында хезмәт

***Хезмәтнең эчтәлеге:***

1. Бүлмә гөлләрен тәрбияләү.
2. Бүлмә гөлләреннән тузан сөртүнең яңа алымы белән таныштыру

***Программа эчтәлеге:***

- Тузан сөртүнең яңа алымы белән таныштыру (юеш пумала белән тузанны чистарту).
- Бүлмә гөлләрен тәрбияләү күнекмәләрен ныгыту: үсемлеккә су сибәргә кирәклеген билгеләү; туфракны дөрес йомшарту, су бөркү, үсемлекләрне юу алымын үзләштерү.
- Дидактик уеннар аша үсемлекләрнең исемнәрен хәтердә ныгыту: “Кайсы үсемлек югалды?”, ”Нәрсә үзгәрде?”.
- Бүлмә гөлләрен тәрбияләүгә кызыксыну уяту, иптәшләренең эшенә дөрес бәя бирергә өйрәтү, яшьтәшләренең уңышына шатлану хисе тәрбияләү.
- Хезмәт турында мәкальләр әйтү.

***Җиһазлар:*** алъяпкычлар, чүпрәкләр, таякчыклар, пумалалар, пульвизаторлар, су сипкечләр, су, сулы табаклар.

***Алдан үткәрелгән эшләр:***

1. Табигать почмагында балалар белән индивидуаль эш.
2. Үсемлекләр турында альбом карау.
3. Үсемлекләр турында әңгәмә.
4. Мәйданчыктагы үсемлекләрне күзәтү һәм тәрбияләү.
5. Хезмәт турында мәкальләр өйрәнү.

***Барышы:***

1. Балалардан сорарга: ни өчен хәзер урамда чәчәкләр үсми?

*Балалар җавабы:* салкын, җир туңган.

2. Ни өчен безнең үсемлекләр яхшы үсә. ә кайберләре чәчәк ата? *Җаваплар:* "Төркемдә җылы, якты. Үсемлекләр яхшы үссен өчен, без аларны тәрбиялибез".
3. Үсемлекләр яхшы үссен өчен без нинди эшләр башкарабыз? Җаваплар: су сибәбез, туфрагын йомшартабыз, су бөркибез, яфракларыннан тузан сөртәбез.
4. Үсемлеккә су сибәргә кирәклеген ничек беләбез? Җавап: "Туфрагын тотып карыйбыз. Әгәр туфрагы дымлы булса, су сибәгә кирәкми".
5. Ничек дөрес итеп су сибәргә?
6. Ничек дөрес итеп туфрагын йомшартырга?
7. Табигать почмагында ни өчен эшләргә кирәк соң?
8. Нинди бүлмә гөлләрен беләсез? Җаваплар: кактус, яран гөле һ.б.
9. Сезнең өстәлләрдә ниди гөлләр?
10. Нинди гөлләргә су бөркергә кирәк?
11. Нинди гөлләрнең яфракларын чүпрәк белән сөртәләр?

Балалар, сез ничек уйлыйсыз, ә бу гөлне чүпрәк белән сөртергә ярыймы? (Кактусны күрсәтергә.) Ни өчен аны сөртмиләр? Балалар, мин сезне хәзер кактустан тузан сөртергә өйрәтәм. Тузанны зур дымлы пумала белән сөртәләр (күрсәтергә. Берәр баланы чакырып чыгарырга һәм баладан күрсәттерергә). Кышын кактусларга суны бик аз сибәләр, кышын алар ял итәләр һәм үсми диярлек..

Ә хәзер "Кайсы үсемлек югалды?" дип аталган уен уйнап алабыз.Үсемлекләр белән икенче төрле уйнарбыз. Уен "Нәрсә үзгәрде?" дип атала. Уен өчен түбәндәге бүлмә гөлләре алына: лилия, исле яран гөле, кактус, фиалка, бүлмә винограды. Биш үсемлек.

Ә хәзер барыгыз да басыгыз, урындыкларны этеп куегыз һәм алъяпкычлар киегез. Сезгә тырышып эшләргә кирәк.

Хезмәт барышында балаларның хезмәт күнекмәләрен дөрес кулланыуы, чиста-пөхтә һәм бердәм эшләве артыннан күзәтү. Эштән соң балалардан хезмәт турында нинди мәкальләр белүләрен сорау.

1.Тирләп эшләсәң, тәмләп ашарсың.

2. Тырышлык – зурлык, ялкаулык – хурлык.

3. Кем эшләми, шул ашамый.

4. Уйна да көл, эшли дә бел.

5. Бүгенге эшне иртәгәгә калдырма.

## *ЯШЕЛЧӘ КИБЕТЕНДӘ САТУЧЫ ХЕЗМӘТЕ БЕЛӘН ТАНЫШТЫРУ*

### Сөйләм үстерүшөгыле. Өлкәннәр хезмәте белән таныштыру.

***Программа эчтәлеге:***

1. Яшелчә кибетендә эшләүче сатучының хезмәте белән таныштыру.
2. Сорауларга грамматик яктан дөрес, тулы җөмләләр төзеп җавап бирү. Сөйләмдә сатучының һөнәри хәрәкәтләрен аңлатучы сүзләрне

кулланырга өйрәтү. Яшелчәләрнең исемнәрен һәм аларга хас сыйфатларны атау.

3. Өлкәннәр хезмәтенә мәхәббәт тәрбияләү, үзара дустанә мөнәсәбәт булдыру.

***Сүзлекне баету:*** яшелчә кибете, сатучы, сатып алучы, кассир, витрина, киштә, үлчәү, герләр. Яшелчәләр: бәрәңге, чөгендер, суган, кишер, кәбестә, җиләк-җимешләр, алма.

***Алдан эшләнгән эш:*** максатлы күзәтүләр, сюжетлы-рольле уеннар "Кибет", "Яшелчә һәм җиләк-җимеш бакчасы”. Яшелчәләр белән уеннар: "Лото", "Парлы рәсемнәр”, “Җыелма рәсемнәр”, сөйләм үстерү, рәсем, әвәләү шөгыльләре. “Кибет” рәсемен карау.

***Шөгыльнең барышы***:

Балалардан сорау: "Балалар, ә сез беләсезме, алма, кәбестә, кишерне әниләрегез каян ала икән? Бүген без сезнең белән шул кибеткә барырбыз. Кибеткә килгәч бөтен җирие күзәтү, яшелчәләр куелган киштәләрне карау. *Табышмаклар әйтү:*

- "Ормый-сукмый, үзе кешене елата” (суган ).
- “Җир астында алтын казык" (кишер).
- "Кат- кат тунлы, карыш буйлы" (кәбестә).
- "Тәрәзәсе юк, ишеге юк, эче тулы халык" (кыяр).
- "Кечкенә генә йорт, эче тулы корт" (кыяр).

Балалар, ә сез үзегез яшелчәләр турында нинди табышмаклар бсләсез? Балалар, без нинди кибеткә килдек әле? Яшелчә кибетенә. Бу кибеттә җиләк-җимеш тә саталар. Табышмак әйтәм: "Алма!” – дисәң дә, алалар, нәрсә соң ул, балалар?” Әйе, алма.

Кибеттә кем эшли? (Сатучы. Ул яшелчә, җиләк-җимеш сата, яшелчәләрне үлчи. Сатучы сатып алучыларга яшелчәләрне сайлап алырга булыша, күпме түләргә икәнен санап бирә). Сатып алучы сатучыга рәхмәт әйтә. Сатучы ничек киенгән? (Ак халаттан, пөхтә итеп киенгән). Балалар, кибеттә тагын кем эшли? (Кассир. Ул алган әйбер өчен чек суга, сатып алучы акча түли). Кибеттә тыныч, якты. Сатып алучылар күп булса, алар чиратка басып кирәкле әйбсрләрен алалар. Балалар, без сезнең белән нинди кибеттә булдык? Анда кемнәр эшли? Сатучы нишли? (Сата, үлчи, саный). Сатып алучы нишли? (Сайлый, сатып ала, рәхмәт әйтә) . Кассир нишли? *(Акча ала, чек бирә).*

*Йомгаклау:*

Сатучы һөнәре бик кирәкле, файдалы, кызыклы. Без кибеттә еш булабыз. Һәм үзсбезгә кирәклс әйберләрне сатып алабыз. Сатучылар белән ягымлы булырга, хезмәттләрен хөрмәтләргә, кибеттә тәртип сакларга кирәк.

## МЕТОДИК РЕКОМЕНДАЦИЯЛӘР

Бу яшьтә балалар барлык эшләрне дә мөстәкыйль башкаралар, коллектив белән хезмәт итәләр. Тәрбияче башкарылган эшнең нәтиҗәсенә, сыйфатына зур игътибар бирә. Балалар эшләреннән даими күргәзмәләр оештырыла.

Балаларның кызыксынуларын исәпкә алып төрле түгәрәк эше алып барыла.

Барлык төр хезмәт, профессияләр белән дә таныштырыла, киләчәктә профессия сайлауга нигез салына.

### *Диагностика*

| *Бурычлар* | *Зурлар хезмәте белән таныштыру* | | | | *Кул хезмәте* | | | | *Хуҗалык-көнкүреш хезмәте* | | | | | | | | | | *Табигатьтәге хезмәт* | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | | | *Дежур тору* | | | | | | | | | |
| | Хезмәт төрләре, анын эчтәлеген белүләре | | Төрле һөнәр ияләренен хезмәтен бәяләү | | Кәгазь, картон, тукыма белән эшли белүләре | | Табигать, ташландык материаллар белән эш | | Коллектив хезмәт | | Кушкан эшне үтәү | | Ашханәдә | | Шөгыльләрдә | | Табигать почмагында | | Табигать почмагында эш | | Балалар мәйданчыгындагы, бакчадагы хезмәт | |
| Ф.И.О. | Б | А | Б | А | Б | А | Б | А | Б | А | Б | А | Б | А | Б | А | Б | А | Б | А | Б | А |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

*Шартлы билгеләр:*

- бик яхшы (кызыл төстә);
- яхшы (зәңгәр төстә);
- уртача (яшел төстә)
- түбән (соры төстә)

Б- ел башы, А – ел ахыры.

## ПЕРСПЕКТИВ ПЛАН

### Конструкцияләү, кул эше (конструирование, ручной труд).

| | *Сентябрь* | *Октябрь* | *Ноябрь* |
|---|---|---|---|
| 1 | Табигать материаллары белән эш. “Кош” ясау. | Кәгазь белән эш. “Тартма” ясау. | Ташландык материал белән эш. Шырпы капла рыннан машина ясау. |
| 2 | Табигать материаллары белән эш. Татар милли үрнәкләрен кулланып панно ясау. | Кәгазь белән эш. “Өй”, яки “Гараж” ясау. | Конструкцияләү. Төзү материалын нан “Күпер” |
| 3 | Ташландык материал белән эш. Поролоннан “Куян” ясау. | Кәгазь белән эш. “Арба” ясау. | Табигать материаллары белән коллектив эш “Йорт кошлары” |
| 4 | Конструкцияләү. ЛЕГО. Теләк буенча. | Конструкцияләү. Конструктордан “Самолет” ясау. | Кәгазь белән эш. “Чыршы уенчыклары” ясау. |
| | *Декабрь* | *Январь* | *Февраль* |
| 1 | Кәгазь белән эш. “Чыршы уенчыклары” ясау. | Ташландык материал белән эш. Поролоннан “Кар бабай” ясау. | Татар орнаменты белән чигү. “Әниемә матур чәчәк” |
| 2 | Кәгазь белән эш. Татар орнаменты белән ковер ясау. | Конструкцияләү. ЛЕГО. Теләк буенча | Кәгазь белән эш. “Әтиемә - ракета” |
| 3 | Кәгазь белән эш. “Чыршы уенчыклары” ясау. | Конструкцияләү. Төзү материалын нан “Мәчет” | Татар орнаменты белән чигү. “Әниемә матур чәчәк” |
| 4 | Кәгазь белән эш. “Чебурашка” ясау | Төймә тагарга өйрәнү. | Татар орнаменты белән чигү. “Әниемә матур чәчәк” |
| | *Март* | *Апрель* | *Май* |
| 1 | Кәгазь белән эш. “Китап” | Кәгазь белән эш. “Паруслы көймә” ясау. | Татар орнаменты белән чигәргә өйрәнүне дәвам итү. |
| 2 | ЛЕГО | Чүпрәк белән эш. Капчык тегү. | Ташландык материал белән эш. Савытлар ясау. |
| 3 | Ташландык материал белән эш. Тимерчыбыктан “Фигура” ясау. | Ташландык материал белән эш. “Обруч” ясау. | ЛЕГО |
| 4 | Конструктор белән эш. “Өй” | Чүпрәк, поролон белән эш. Энә кадагыч ясау. | Конструктор белән эш |

## ПЕРСПЕКТИВ ПЛАН

### Үз-үзеңә хезмәт күрсәтү. Хуҗалык-көнкүреш хезмәте

| *Айлар* | *Үз-үзеңә хезмәт күрсәтү* | *Хуҗалык-көнкүреш хезмәте* |
|---|---|---|
| Сентябрь | Киенүдәге тәртипсезлекне бетерү, киемне һәм аяк киемен саклау. | 1. Ашханәдә һәркөнне дежур тору.<br>2. Яшелчә бакчасында уңыш җыю.<br>3. Һәркөнне мәйданчыкны җыю. |
| Октябрь | Таракны, кульяулыкны куллана, ашаганнан соң авызны чайкый, йокларга ятканда теш чистарта белү | 1. Һәркөнне шөгыльләрдә дежур тору.<br>2. Коллектив хезмәт вакытында бер-береңә ярдәм итү. |
| Ноябрь | Дөрес ашау, приборларны ашагач илтеп кую, өстәлне сөртү. | 1. Үз эш урыныңны җыю.<br>2. Курчак керләрен юу.<br>3. Урын-җирне җыештыру. |
| Декабрь | Урын-җирне җәя белү, тузан сөртү, уенчыкларны җыю. | 1. Һәркөнне табигать почмагында дежур тору.<br>2. Җиһазлардан тузан сөртү.<br>3.Юлларга ком сибү. |
| Январь | Кием шкафын тәртиптә тоту. | 1. Йокыдан соң урынны җыю.<br>2. Китапларны ремонтлау.<br>3. Кардан төрле корылмалар ясау.<br>4. Урам җыештыручы һөнәре белән таныштыру. |
| Февраль | Мәйданчыкта юлларны чистарту, тау ясау, киемнәрне киптерү. | 1.Урын-җирне алмаштыруда тәрбияче ярдәмчесенә булышу.<br>2.Китапларны ремонтлау. |
| Март | Киемне чиста тоту, киемдәге тәртипсезлекне бетерү, иптәшеңә ярдәм итү. | 1.Чиста урын-җир әйберләрен караватларга тарату.<br>2.Киемнәрне прогулкадан соң киптерү.<br>3.Эш урынын җыештыру. |
| Апрель | Һәркөнне төркемне җыю, тәртиптә тоту. | 1. Өстәл уеннарын тәртипкә китерү.<br>2. Комны казу.<br>3. Кечкенә балаларга мәйданчыкларын җыештырырга булышу. |
| Май | Пөхтә итеп киенү, чәчне тәртиптә тоту. | 1. Үз урын-җиреңне әзерли белү.<br>2. Урамда уйнау өчен уенчыклар ясау. |
| Июнь<br>Июль | Алган белемнәрне ныгыту. | 1. Һәркөнне комны казу, веранданы себерү. |

| | | |
|---|---|---|
| Август | | 2. Һәркөнне уенчыкларны юу.<br>3. Мәйданчыкны тәртиптә тоту.<br>4. Су сибү.<br>5. Һәркөнне яшелчә бакчасында эшләү. |

## ПЕРСПЕКТИВ ПЛАН

### Табигатьтә хезмәт. Табигать почмагында хезмәт.

| ***Айлар*** | ***Табигатьтә хезмәт*** | ***Табигать почмагында хезмәт.*** |
|---|---|---|
| Сентябрь | 1. Бакчада уңыш җыю.<br>2. Түтәлләрне чистарту, казу, георгин, гладиолус суганчаларын казып алып, сакларга кую.<br>3. Чәчәк орлыклары җыю | 1. Һәркөнне гөлләрне карау, дөрес су сибәргә өйрәтү<br>2. Яшел суган үстерү<br>3. Урамдагы гөлләрне күчереп утырту. |
| Октябрь | 1. Кипкән букет ясау өчен чәчәкләр әзерләү.<br>2. Үз куллары белән уенчыклар ясау өчен табигать материаллары туплау. | 1. Һава торышын календарьдә билгеләп бару.<br>2. Кипкән яфраклардан, орлыклардан картина ясау. |
| Ноябрь | 1. Һәркөнне кошларны ашату өчен җимлекләр элү.<br>2. Агач төпләренә кар өю.<br>3. Утыргычларны, юлны кардан чистарту. | 1. Дежурныйлар календарь тутыралар.<br>2. Көз, көзге эшләр турында рәсемнәр урнаштыру. |
| Декабрь | 1. Һәркөнне мәйданчыкны җыештыру.<br>2. Юлларга ком сибү<br>3. Чыршы бизәү. | 1. Солы чәчү.<br>2. Тәҗрибә ясау, үсемлекләргә үсү өчен җылы һәм якты кирәк.<br>3. Кошларны күзәтү. |
| Январь | 1. Һәркөнне кечкенә төркем балаларын чанада тартып йөрү, мәйданчыкларын кардан чистартырга булышу.<br>2. Тау ясауда катнашу. | 1. Арпа чәчү.<br>2. Суган, сарымсак утырту.<br>3. Кошларны тәрбияләргә өйрәтүне дәвам итү. |
| Февраль | 1. Кардан крепость ясау. | 1. Кар һәм бозны чагыштыру. |
| Март | 1. Сыерчык оялары элү.<br>2. Мәйданчыкны кардан чистарту, кышны озату бәйрәменә әзерләнү. | 1. Бүлмә гөлләре утырту, күчереп утырту.<br>2. Чәчәк орлыклары утырту. |
| Апрель | 1. Бакчада язгы эшләрдә катнашу. | 1. Беренче язгы чәчәкләрне, бөреләрнең ачылуын күзәтү. |

| | | |
|---|---|---|
| Май | 1. Бакчада су сибү эшендә катнашу.<br>2. Түтәлләргә яшелчәләр утыртуда катнашу (редиска, кишер). | 1. Әкәм-төкәмне күзәтү.<br>2. Урман кошларының, төрле чәчәкләрнең рәсемнәрен карау. |
| Июнь<br>Июль<br>Август | 1. Һәркөнне түтәлләргә су сибү, чүпләрен утау, чүп үләнен таныргa өйрәтү.<br>2. Дару үләннәреннән гербарий ясау.<br>3. Укроп чәчү.<br>4. Түтәлләрне казу, чүпләрен җыю.<br>5. Төрле әйберләр (поделка) ясау өчен яфраклар җыю. | 1. Дару үләннәренең рәсемнәрен карау, әһәмиятен аңлату.<br>2. Урамдагы чәчәклеккә яран, кына, юкә гөлләрен күчереп утырту.<br>3. Табигатьне саклау турында рәсемнәр ясау. |

## ПЕРСПЕКТИВ ПЛАН

### Тегүче хезмәте белән таныштыру.

| ***Айлар*** | ***Эчтәлеге*** |
|---|---|
| Сентябрь | 1. Тегүченең ничек эшләвен күзәтү.<br>2. Төрле киемнәр карау. |
| Октябрь | 1. Балаларның өйдә әни-әбиләренең нәрсәләр тегүе турында әңгәмә.<br>2. Киемнәр тегү фабрикасына (ателье) экскурсия. Кемнәр эшли, кемнәр өчен, нинди киемнәр тегәләр. |
| Ноябрь | 1. Картина карау. “Тегүче”.<br>2. Төрле тукыма үрнәкләре белән танышу. Нинди тукымадан күлмәк, костюм, пальто һ.б. тегәләр. Әзер тегелгән киемнәр карау.<br>3. “Тегүче” уены өчен атрибутлар әзерләү (тукыма үрнәкләре, кисү өчен шаблоннар, тегү машиналары). |
| Декабрь | 1. Балаларны тегәргә өйрәтү. Кием кисү өчен кулланыла торган шаблоннар белән эшләргә өйрәтү.<br>2. Бәйләү фабрикасына экскурсия. Башлык, бияләй, шарфларны ничек бәйлиләр. Бәйләү машиналарын күзәтү. Җепләрне каян алалар. Җеп ясау өчен йонны каян алалар. |
| Январь | 1. Рәсем ясау “Спорт костюмындагы чаңгычы”.<br>2. Тегү фабрикасында эшләүче кешеләр хезмәтен чагылдыручы альбом ясау. |
| Февраль | Дидактик уен “Эш өчен кемгә нәрсә кирәк?” |
| Март | Матур әдәбият әсәрләре уку. “Сарафанчик” Александрова, Р.Валиева “Кәләпүшем, кәләпүш”. |
| Апрель | 1. Әңгәмә. “Барлык эшләр дә яхшы, күңел биреп башкарсаң”<br>2. Тегүче булып эшләүче белән очрашу. |

## ПЕРСПЕКТИВ ПЛАН

### Чигәргә өйрәтү.

***Максат:*** балаларның декоратив-гамәли сәнгатебез турындагы белемнәрен тирәнәйтү. Орнамент турында алган белемнәрне чигүдә кулланырга һәм җеп, энә белән эшләргә, бизәкне тукымага төшерергә һәм төрле чигү җае белән чигәргә өйрәтү. Чигү осталарының эшенә кызыксыну тәрбияләү**.**

| ***Айлар*** | ***Эчтәлеге*** | ***Максат*** |
|---|---|---|
| Сентябрь | Чигүле әйберләр карау. Куркынычсызлык кагыйдәләрен өйрәтү. | Халкыбызның милли һөнәр осталыгы белән таныштыру. Матурлыкка сокланырга өйрәтү, шул матурлыкны тудырырга теләк уяту. Кайчы белән сак эшләргә, энәне авызга алмаска, җепсез килеш кулдан-кулга бирмәскә, ә тукымага кадап бирергә кирәклеген аңлату. |
| Октябрь | Энәгә җеп сапларга, җеп очын төенләргә өйрәтү | Куркынычсызлык кагыйдәләрен ныгыту. Күз үткерлеген үстерү. Бармакка җепне урап, артык зур итмичә төен төйнәү. |
| Ноябрь | Бер уң яктан, бер сул яктан энәне кертеп, иң гади җөй чигәргә өйрәтү. | Төенне тукыманың сул ягында калдырып чигә башларга, энәне өч бармак белән дөрес итеп тотарга, тигез ара калдырып чигәргә өйрәтү. |
| Декабрь | Өйрәнелгән җөй белән кояш, квадрат, өчпочмак чигү. | Энәне дөрес итеп тотып, тигез атлатып төрле юнәлештә чигәргә, җеп беткәч, тукыманың тискәре ягында төйнәп куярга өйрәтү. |
| Январь | 1. Йөртеп чигүне (сабаксыман чигеш) өйрәтә башлау.<br>2. Күбәләк силуэтын йөртеп чигү. | Вак кына атлатып йөртеп-йөртеп чигәргә өйрәтү. Энәне үзеңнән читкә каратып чигү, туры сызык буйлап чигеп бару.<br>Вак кына атлатып, төрле юнәлештә чигәргә өйрәтү. |
| Февраль | 1.Йөртеп чигү алымы белән чәчәк чигү.<br>2. Әниләргә бүләккә кулъяулык чигү. | 1. Теләгән төсләрне сайлап, тукыманы җыермыйча чәчәк, сабак, яфрак чигүне өйрәтү. Хезмәтнең нәтиҗәсенә куану.<br>2. Алда өйрәнгәннәрне ныгыту: йөртеп чигү алымы белән чәчәк чигү; гади җөй белән кулъяулыкның читен читләү. Үз эшең белән горурлану хисе тәрбияләү, якыннарыңа сөенеч китерү теләге уяту. |

| | | |
|---|---|---|
| Март | 1. Әниләр бәйрәменә балалар эшләреннән күргәзмә оештыру.<br>2. Чылбыр җөй (тамбурлы чигү) өйрәнә башлау. | 1. Әниләргә хөрмәт тәрбияләү, аларда балалары белән горурлану хисләре уяту. Эшнең нәтиҗәсенә куану.<br>2. Энәне ике катлы җепнең уртасыннан чыгарып чылбыр җөй чигәргә өйрәтү. Чылбырны тигез ара калдырып, туры сызык буйлап чигеп бару. |
| Апрель | Чылбыр җөй белән песи, эт силуэтларын чигү. | Төрле юнәлештә чылбыр җөй белән чигәргә өйрәтү. Вак кына атлатып, борылышларда тукыманы тарттырмыйча, матур итеп чигәргә күнектерү. |
| Май | Балалар эшләреннән күргәзмә оештыру. | |

***ШӘФКАТЬЛЕЛЕК БИЗИ КЕШЕНЕ***

**Кул эше шөгыле. Кәгазьдән муенса ясау.**

***Программа эчтәлеге:***

- Балаларны кәгазьдән муенса ясарга, кэгазьне дөрес итеп карандашка чорнарга өйрәтү.
- Җепкә тезгәндә дөрес чиратлаштырып, ритмик рәсем ясап тезәргә өйрәтү, балаларның логик фикерләү сәләтләрен үстерү.
- Балаларны Хәйрия елы эмблемасы белән таныштыру. Яхшы эшләр эшләргә рухландыру. Кешелеклелек, ярдәмчеллек, изгелек сыйфатлары тәрбияләү. Нәниләргә карата һәрвакыт кайгыртучанлык хисләре тэрбиялэү, аларны рәнҗетмәү.

***Җиһазлау:*** магнитофон, аудиокассеталар, курчак.

***Курсәтмә материал:*** Хәйрия елы эмблемасы рәсеме. Муенсалар.

***Таратма материал:*** Һәр балага дүртәр киселгән төсле кәгазь (30 см х 3 см, өчпочмак формасында). Ике балага бер җеп – шнур.

***Сузлек остендә эш:*** Хәйрия елы, изгелек, шәфкатьлелек, алиһә.

***Методик алымнар:*** әңгәмә, сораулар, проблемалы сораулар, уен, практик эш, нәфис сүз куллану.

***Алдан эшләнгән эш:*** физминуткалар өйрәнү, таратма материалларны әзерләү, кәгазьне карандашка чорнарга өйрәтү,

***Индивидуаль эш:*** пассив балалар белән алдан шөгыльгә әзерләнү, кызыксындыру.

***Шогыльнен структурасы:***

**1.** Оештыру.

Балалар кунакларга карап басалар. Исәнләшәләр. Тәрбияче балаларны “Яхшылык” алиһәсе белэн таныштыра. “Яхшылык” иленә кунакка чакыра. (Музыка уйный.)

**2.** Төп өлеш.

- Рәсемне күрсәтеп әңгәмә үткәрү.
- Эшне аңлату.
- Физминутка. Бармакларны әзерләү.
- Балаларның эшләре. Музыка уйнап тора.

**3.** Йомгаклау.

Муенсаларны нәни балаларга бүләк итү.

***1.*** *Оештыру*. Исәнмесез, балалар. Мин – Гүзәл Илдусовна. Мин сезнең янга үземнең дустым белән килдем. Ул “Яхшылык” алиһәсе. Сезне үзенең иленә - “Яхшылык иле”нә кунакка чакыра. Барабызмы, балалар? (Музыка уйный, балалар күзләрен йомалар, күз ачып йомганчы бу илгә килеп тә җитәләр).

***2.*** *Төп өлеш.* (Тәрбияче Хәйрия елының рәсемен күрсәтә) Балалар, карагыз әле, кемнең бу рәсемне күргәне бар? Кайда? (Балаларның җаваплары). Ничек уйлыйсыз? Бу илнең исеме ничек икән? (ТАТАРСТАН). Әйе, бу рәсем Хәйрия елының эмблемасы. Ул һәрвакыт яхшы эшләр эшләргә кирәклеген искәртеп тора.

Ә сез нинди яхшылыклар эшли аласыз? Бүген мин сезне ДУСТЫМ белән 1 яхшылык эшләргә өйрәтәсем килә. Әйдәгез, без сезнең бакчадагы кечкенә балаларга муенсалар ясап бүләк итик. Алар бит кечкенәләр, үзләре ясый белмиләр. Бу муенсалар ярдәмендә алар төсләрне белерләр, җепкә төймәләрне тезәрләр, нәтиҗәдә яхшы итеп сөйләшергә өйрәнерләр.
Сезнең өстәлләргә ясалып бетмәгән муенсалар куйдым, сез һәрберегез 4 – әр төймә ясап, җепкә төсләрне дөрес итеп чиратлаштырып тезәрсез.
Башта кәгазьне клейлыйбыз, соңнан аны карандашка киң ягыннан чорныйбыз, әкрен генә тартып чыгарабыз, соңнан җепкә тезәбез. *(Күрсәтә)*.

- Ә хәзер ясый башлаганчы бармакларны эшкә әзерлик. Бастык.
- Без кәбестә турыйбыз: әйбәтләп тоз сибәбез.
- Кишерне дә уабыз, әйбәтләп болгатабыз. Суын да чыгарабыз, дару итеп эчәбез.
- Балаларның эшләре. (Музыка уйный, тәрбияче авырсынган балалар белән индивидуаль эш алып бара).
- Балалар ясап бетергәч, “Яхшылык” алиһәсенә китерәләр. Тәрбияче бүләк муенсаларны алиһәнең матур тартмасына салырга булыша.

***3.*** *Йомгаклау.* Балалар, сезгә “Яхшылык” илендә ошадымы? Ә хәзер әйдәгез бакчага кайтыйк. Алиһә дә безнең белән кайта. Ул сезне һәрвакыт яхшылык эшләргә өндәп торыр. Алиһә сезнең муенсаларыгызны бик ошатты. Алар пөхтә, төсләре дөрес аралаштырып тезелгән, ныклы, матур. Алар безнең нәниләребезгә дә ошар. Ул сезне бик яратты. Сездән яхшы эшләр көтә һәм үзенең биюен бүләк итә.

Балалар, сез бик тырышып эшләдегез. Минем дә сезгә бүләгем бар. (Бирә). Эш беткәч уйнарга да ярый.

Ә хәзер кемнәр матур җаваплар бирде, алар белән бүләк тапшырып киләбез.

## *ЯШЕЛЧЕ БАКЧАСЫНДА КИШЕР, САЛАТ, КЫЯР УТЫРТУ*

**Табигатьтә хезмәт.**

***Максат:*** балаларга яшелчәләрнең орлыклардан үсүен аңлату; кишер, салат, кыяр орлыкларын аерырга өйрәтү (салат орлыклары яссы, овал формасында, күк төстә; кишер орлыклары бик кечкенә, соры төстә, энәле; кыяр орлыклары яссы, овал формасында, ак төстә); чәчү алымнары белән таныштыру.

Балаларда яшелчә үстерәсе килү теләге тәрбияләү. Бергәләп эшләүдән тәм, шатлык, куаныч табарга өйрәтү.

***Сүзлекне баету:*** бразна, салат, үлчәү таяклары, маркер, этикетка.

***Җиһазлау:*** кишер, салат, кыяр орлыклары, үлчәү таяклары - 20 см – 2 данә; 25 см – 2; 8 см – 2; 35 см – 2, маркер – 2, шнур – 1, җир белән чиләкләр – 6, совоклар – 6, лейкалар – 6, песок, салат, кишер, кыяр рәсемнәре төшерелгән этикеткалар, посылка, орлык салынган пакетлар, яшелчәләр (кишер, чөгендер, кыяр, суган).

***Алдан эшләнгән эш:*** түтәлләр әзерләнгән. Су сибелгән.

***Оештыру:***

*1 өлеш. Төркем бүлмәсендә үтә.*

Утырту өчен орлыклар әзерләнгән: кишер, салат орлыклары ком белән бутап куелган; кыяр орлыклары су белән чылатылган. Яссы савытларда карау өчен орлыклар салынган, ак кәгазь битләре.

1. *Дидактик уен.* «Почтальон посылка алып килгән» (кемдер ишек шакый)

– Кем бар?

– Бу мин – почтальон. Сезгә посылка алып килдем.

– Рәхмәт.

– Соравыма җавап бирсәгез, посылканы бирәм. Яшелчә бакчасында нәрсәләр үсә? (Яшелчәләр!) Яшелчәләр турында табышмаклар да әйтегез инде. Балалар табышмаклар әйтәләр.

*2. Тәрбияче посылканы ача, анда орлык салынган пакетлар.*

– Балалар, яшелчәләр нәрсәдән үсә? (Орлыклардан).

– Үткән ел без сезнең белән нәрсәләр утырткан идек?

– Сез аларны ничек үстердегез?

– Бүген мин сезгә салат, кишер, кыяр утыртырга тәкъдим итәм. Кәгазьгә салат, кишер, кыяр орлыкларын салыгыз.

– Алар нәрсә белән аерылалар? (Салат, кишер орлыклары вак, ә кыярныкы эре).

– Салат, кишер орлыклары нәрсәсе белән охшаш? (Алар вак, яшелчәләр үсеп чыга).

– Вак орлыкларны ничек утыртырга? (Вак орлыкларны ком белән бутарга кирәк, тәрбияче күрсәтә - бу орлыклар тигез тишелсен өчен, куе булмасын өчен шулай эшләнә).

***2 өлеш.***


Яшелчә бакчасына килгәч, балаларны өч төркемгә бүләм. Һәр төркем бер түтәл утырта. Кишер һәм салат орлыкларын ничек утыртырга кирәклеген аңлатам. Буразналар ясыйбыз. Үлчәү таягы белән буразна араларын билгелибез, ә маркер белән буразналар сызабыз. Маркер белән буразнаны басыбрак берничә тапкыр сызабыз, буразнаның төпләрен учның кырые белән тыгызлыйбыз.

Ком белән буталган кишер һәм салат орлыкларын әз генә алабыз һәм буразна буйлап кулны әкрен генә йөртеп сибәбез (тирәнлеге = 1 см).

*Кишер, салат утырту*




*Кыяр утырту*




Кыяр орлыкларын ничек утыртырга икәнен аңлатам. Түтәлдә бер генә буразна сызабыз. Чөнки кыяр үсентеләренә урын күп кирәк, алар бик зур булып, җәелеп үсәләр. Үлчәү таягы белән түтәлнең уртасын йомшартабыз, шнур ярдәмендә буразна сызабыз. Кыяр орлыкларын тигез ара калдырып берәр генә итеп буразнага салабыз. Үлчәү таягын күрсәтәм, ул 8 см га тигез, бу кыярлар арасы, ә таякның буялган өлеше ул тирәнлекне күрсәтә (3 см). Шул тирәнлектә орлыкларны салабыз.

***3 өлеш*. *Балалар эшлиләр.***

Кемнәр кишер һәм салат утырта, балалар түбәндәгечә эшне бүлешәләр: беренче пар үлчәү таягы белән буразна урыннарын билгели, икенче пар маркер белән буразна ясый, өченче пар уч кырые белән буразнаның төбен тыгызлый, дүртенче пар орлыкларны буразнага сала, бишенче пар чиләккә салынган җирне совок белән алып орлыкларны каплый. Беренче пар эшен бетерүгә су сибәләр.

Кемнәр кыяр утырта, балалар түбәндәгечә эшне бүлешәләр. Беренче пар буразна урынын билгели, икенче пар шнур тота, өченче пар уртадан буразна сыза. Беренче пар 8 см лы үлчәү таягы белән кыярларны утырту

урынын билгели, икенче пар утырта (тамырын аска каратып, җиргә куеп), өченче пар җир белән каплый. Беренче пар су сибә.

Тәрбияче кайда балалар читенсенә ярдәмгә ашыга, булыша. Эшне бетергәч, этикеткалар кадап куела.

***4өлеш. Йомгаклау.***

- Яшелчәләр яхшы үссен өчен нәрсә эшләргә кирәк? (Су сибәргә, йомшартырга, чүпләрен утарга, сирәкләргә).
- Балалар, сез бик яхшы, тырышып эшләдегез. Яшелчәләребез мул, зур булып үсселәр дигән теләктә калыйк.

## *ХЕЗМӘТ ТӨБЕ – ХӘЗИНӘ*

### Хуҗалык - көнкүреш хезмәте. Төркем бүлмәсен җыештыру

***Программа эчтәлеге:*** хезмәткә карата уңай мөнәсәбәт, хезмәт сөючәнлек, кызыксынучанлык тәрбияләү. Үз өстеңә йөкләнгән эшне тырышып, ахыргача башкарып чыгарга өйрәтү. Эшләү вакытында эшне планлаштырырга, вазифаларны тигез бүлә белергә күнектерү. Иптәшләреңнең эш гамәлләренә карата уңай мөнәсәбәт, үзара ярдәмләшү хисе тәрбияләү.

***Җиһазлар:*** табаклар, су сипкечләр, алъяпкычлар, чүпрәкләр.

***Коллектив хезмәт үткәрүнең барышы:***

- Балалар, хезмәт турында мәкальләр беләсезме?
  1. Хөрмәтнең төбе – хезмәт.
  2. Кем эшләми, шул ашамый.
  3. Тырышкан табар, ташка кадак кагар.
- Сез, балалар, хезмәт итәргә яратасызмы? Без бүген төркемебезне бергәләп җыештырабыз. Төркемдә чисталык, пөхтәлек булсын өчен нишләргә кирәк?
  - Уенчыклар киштәләрендә тәртип урнаштырырга кирәк.
  - Бүлмә гөлләрен юарга.
  - Төзү материалларын сөртергә.
  - Курчак почмагында кием-салым, урын-җирне алыштырырга.

Балалар, мин хәзер кемнең кем белән эшләвен һәм нинди эш башкаруларын әйтәм:

1 нче звено: Булат, Марианна, Айдар, Алсу.

2 нче звено: Алмаз, Алинә, Эльвира, Алсинә.

3 нче звено: Эльвина, Айдар, Айнур. Бу балалар киштәләрне җыештыралар.

4 нче звено: Илсур, Лиана, Руслан төзү материалларын сөртәләр.

5 нче звено: Чулпан, Алинә, Карина, Гүзәл. Сез гөлләрне юарсыз.

- Балалар, әйтегез әле, эшкә керешкәнче нишләргә кирәк?... Дөрес, кемнең нәрсә эшләячәген үзара сөйләшеп куярга кирәк. Айнур курчакларны матур итеп утыртып куя, ә Эльвира дымлы чүпрәк белән тузаннарны сөртә.

Балаларга эшкә керешергә тәкъдим итү. Эш барышында балаларның игътибарын төркемдә бердәм эшләүгә һәм эшне ахыргача җиткерүгә юнәлтү.

Эш тәмамлангач, инвентарьларны табигать почмагының аскы киштәсенә куярга тәкъдим итү.

Тәрбияче балаларны үз янына чакырып ала да мактый: "Бик яхшы эшләдегез! Беркем дә артка калмады, барыгыз да бердәм тырыштыгыз. Денис, син нинди эш башкардың?... Карина, әйт әле, Айнур ничек тырышты? Алмаз дусларына булыштымы? Ә Айдар ничек эшләде?...

Мәкальләрне искә төшерү:

- "Башлый белсәң бетерә бел, эшеңне җиренә җиткерә бел"
- "Берәү эшли алмаганны – барыбыз бергә эшләрбез".

## *БАКЧА ЯСАМЫЙ, АЛМА БУЛМЫЙ*

### Балаларның табигать почмагында хезмәте

***Хезмәтнең эчтәлеге:***

1. Гладиолус суганчаларын утырту.
2. Бүлмә гөлләрен тәрбияләү.

***Программа эчтәлеге:***

Гладиолус суганчаларын утырту буенча балаларда күнекмәләр булдыру, үсү өчен озак вакыт һәм җылы таләп итүче үсемлекләрне, рассада белән утырту кирәклеге турында белем бирү. суганчаларны чүлмәкләргә утыртып, бүлмәдә үстерергә кирәклеген аңлату.

Бүлмә гөлләрен тәрбияләү буенча күнекмәләрен ныгыту: гөлләргә су сибүнең әһәмиятен аңлату, дөрес итеп гөлләрнең төпләрен йомшартырга һәм юарга, эшне бүлешеп, үзара килешеп эшләргә, иптәшләренең хезмәтенә дөрес бәя бирергә, яшьтәшләренең уңышларына шатлана белергә өйрәтү.

***Әсбаплар:*** чүлмәкләр, таякчыклар, балчык, көрәкчекләр, чүпрәкләр, су, алъяпкычлар.

***Барышы:***

Балаларга бүген табигать почмагында хезмәт итәчәгебез турында әйтү. Сорау:

- Табигать почмагында без нинди хезмәт башкарабыз? (Гөлләргә су сибәбез, төпләрен йомшартабыз, чәчәкләрне күчереп утыртабыз, юабыз, җыябыз һәм башкалар).
- Ни өчен табигать почмагында хезмәт куярга кирәк? (Гөлләр корый, пычрана, искерә. Ямьсез була, гөлләр чәчәк атмый).

Балалар, хәзер мин сезне төркемнәргә бүләрмен, бер төркем бүлмә гөлләрен карар, ә бер төркем суганчалар утыртыр, ә калган балалар табигать материалларыннан уенчыклар ясар. Ләкин эшне башлаганчы безгә кем нинди эшне башкарачак, алдан килешеп куярга кирәк. Шул вакытта гына безнең эшебез яхшы эшләнер. Иптәшләрегездән

калышмаска, бергә эшләргә кирәк. (Балалар кем нинди эшне башкарачак, шул турыда үз фикерләрен әйтәләр, эшне бүлешәләр).
- Киемнәрне, җиңнәрне пычратмас өчен нәрсә эшләргә кирәк? (Балаларның җаваплары).

Эшне башлыйлар.

Суганчаларны утыртучы балаларга бу чәчәкләрнең озак үсүен, шуңа күрә хәзер төркемдә утыртып тәрбияләргә, урамда көннәр җылыткач күчереп утыртырга кирәклеген тагы бер тапкыр сөйләргә, аңлатырга кирәк. Бу үсемлекнең бик тә җылы яратуын, җылыда гына үсүен төшендерергә кирәк. Ничек утыртырга икәнен күрсәтү, балалар үзләре яңадан утырталар.

Эш барышында балаларның эшне пөхтә, теләп, җиренә җиткереп башкаруларына ирешү, бер-берсенә ярдәмчел булуларын ассызыклау. Күзәтеп киңәшләр бирергә, ярдәм итәргә.

***Анализ:*** эшнең ахырында балаларның ничек итеп хезмәт итүләре , бер-берсенә булышулары турында сөйләтү. Балалардан сорарга:
- Башлаган эшебезне башкарып чыга алдыкмы, куелган максатка ирештекме, үзебезгә кушылган эшне ничек үтәдек? (Балаларның җаваплары).

Хезмәт турында мәкальләр искә төшерү. Аларны ничек аңлыйлар шуларны ачыклау.

## *СЕРЛЕ ОРЛЫКЛАР*

### Кул эше шөгыле. Табигый материал белән эш

***Программа эчтәлеге:*** балаларны табигый материал белән эшләргә өйрәтү; бизәк уйлау, кирәкле материалны сайлап алу күнекмәсен, бармакларның эшчәнлеген ныгыту; логик фикер йөртү, иҗади күзаллауны, сәнгать осталыгын үстерү; тирә-юньгә һәм туган як табигатенә мәхәббәт, үз эшеңне, иптәшләреңнең эшен бәяли белүне тәрбияләү.

***Сүзлекне баету:*** панно, орлык, бөртекле культура.

***Җиһазлау:*** кукуруз, фасоль, борчак салынган подночлар, пластилин, чүпрәк, такта, диаметры 10-12 см зурлыктагы картоннан киселгән түгәрәк.

***Индивидуаль эш:*** әйтеп җибәрү, ярдәм итү.

***Алдагы эш:*** гербарийлар карау, “Культуралы үсемлекләр” темасына әңгәмә кору, физминуткалар өйрәнү, үрнәкләр әзерләү.

***Бүлмәне әзерләү:*** үрнәкләрне урнаштыру, өстәлләрне П хәрефе кебек урнаштыру, һәр бала өчен кирәкле әсбаплар хәзерләү.

***Методлар һәм алымнар:*** үрнәкне анализлау, күрсәтү, аңлату, һәр балага индивидуаль якын килү.

***Шөгыльнең төзелеше:***

1. Бөртекле культуралар турында әңгәмә. Орлыклар күрсәтү. Үрнәкне анализлау. Эш тәртибен аңлату.

2. Балаларның эшләре. Физминутка үткәрү.
3. Балаларның эшләрен бәяләү. Күргәзмә оештыру.

***Барышы:***

1. Балалар, көз көне бакчаларда, кырларда, басуларда яшелчә, җиләк-җимеш, бөртекле культуралар өлгерә. Аларны кешеләр аш-су әзерләгәндә кулланалар.

Орлыкларны, ярмаларны кул эше өчен дә кулланалар. Мәсәлән, алардан бик матур декоратив паннолар әзерләргә була. Алар белән бүлмәне бизәргә мөмкин. Без дә бүген кукуруз, борчак, фасольдән бик матур паннолар ясарбыз.

- Карагыз әле, менә шундый озын кузакта фасольләр гаиләсе яши. Алар төрле төстә була. Ә менә бу зур чәкәндә кукуруз орлыклары яши. Шул орлыклардан бик матур паннолар әзерләрбез.

2. Эшне без түгәрәк картон һәм пластилиннан башлыйбыз. Плстилинны тигез итеп картонга сылыйбыз, аннан соң орлыкларны урта өлешкә бизәк ясап тезәбез, соңыннан бизәкне кырыйга ясыйбыз.
3. Хәзер бармакларны эшкә әзерлик.

Пластилинны йомшарталар безнең бармаклар,
Тырышалар, әвәлиләр, ныгыйлар.

Пластилинны өзеп-өзеп алып чиста, пөхтә итеп баш бармак белән сылыйбыз. Картон күренеп калырга тиеш түгел. Киемнәрне, өстәлне пычратмыйбыз. Безгә орлыкларны аерырга кирәк

*Борчак белән уен. Ике кул белән дә уйнала.*

Бармак борчакны ала,
Уйный һәм тәгәрәтә.
Борчак тәгәри өстәлдә,
Бармаклар ныгып кала.

Балаларның эшләре. Аларга ярдәм итү.

4. Әзер панноларны тактада урнаштыру. Балалар эшләрне карыйлар, матурлыгына сокланалар.

- Без бүген бик тырышып эшләдек. Паннолар белән төркемебезне бизәрбез. Башка шөгыльләрдә ярмадан, чикләвек кабыкларыннан паннолар ясарбыз. Балалар, сез бик тырыштыгыз.

“Тырыш кеше – алтын кеше, ялкау кеше – ярты кеше”. Мәкальнең мәгънәсен аңлату.

**Хезмәткә өйрәткәндә кулланырга тәкъдим ителә.**

***Хезмәт турында мәкальләр***

- Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз.
- Һөнәрле үлмәс, һөнәрсез көн күрмәс.
- Хезмәтнең тире ачы булса да, җимеше татлы була.
- Акыллы эшчән булыр, ахмак телчән булыр.
- Хезмәте барның хөрмәте бар.
- Эшләгән корт бал табар,  эшләгән кул мал табар.
- Эш сөйгәнне ил сөяр.
- Эшчән бәхетне эштән күрер, ялкау бәхетне төшендә күрер.
- Эш кешене төзәтә, ялкаулык боза.
- Эш эшләгән интекмәс, эшләмәгән көн итмәс.
- Ялкаулык - хурлык, тырышлык – зурлык.
- Ялкау ялга туймас, эшчән эштән туймас.
- Агач - җимеше белән, кеше - эше белән.
- Аз сөйлә - күп эшлә.
- Хезмәтенә күрә хөрмәте.
- Бүгенге эшне иртәгәгә калдырма.
- Киңәшле эш таркалмас.
- Җәй эшләсәң, кыш ашарсың.
- Эшләп ашасаң, арыш икмәге дә тәмле.
- Эшнең ояты юк.
- Сүзең белән мактанма - эшең белән мактан.
- Ашаганда колагың селкенсен, эшләгәндә йөрәгең җилкенсен.
- Иң-иң татлы, затлы җимеш – тырыш хезмәт җимеше ул.

***Эш кораллары турында табышмаклар***

- Ишекле-түрле йөри, эләккәнне сөйри. *(Себерке)*
- Бәләкәй генә бичура билен буып утыра. *(Себерке)*
- Авызы юк, тешле. *(Пычкы)*
- Җырлый-җырлый әйбер кисә, әйтеп бирче бу нәрсә? *(Пычкы)*
- Тиз ашый, вак чәйни, үзе йотмый, башкага бирми. *(Пычкы)*
- Бер түгәрәктә дүрт тишек. *(Төймә)*
- Ике оч, ике балдак, уртасында бер кадак. *(Кайчы)*
- Ике кулча, уртасында бер төймә. *(Кайчы)*
- Агасы турый, энесе ялгый. *(Кайчы  һәм энә)*
- Бөтен дөньяны киендерә, үзе ялангач.  *(Энә, җеп)*
- Койрыгы - башында, колагы күзендә. *(Энә, җеп)*
- Тек-тек итәр, текмештән китәр. *(Тегү машинасы)*

- Бер чокырда мең чокыр. *(Уймак)*
- Үзе бер, күзе мең. *(Уймак)*
- Кызу табанлы чана, - ат җигелмәгән аңа, - бер чигенә, бер бара, юлы шомарып кала. *(Үтүк)*
- Кораб йөзә килә, күлне көйдерә килә. *(Үтүк)*
- Кечкенә генә үзе, маңгенда күзе, күрсә, онытмый үзе. *(Фотоаппарат*)
- Үзе монда утыра, сүзне тегендә тутыра. *(Телефон)*
- Күрергә күзе юк, сөйләргә теле юк, үзе саный. *(Үлчәү)*
- Аягы йөрми, таягы йөри. *(Чалгы, печән чабу).*
- Кош та түгел, ат та түгел, үзе оча, йөк ташый. *(Самолет)*
- Аккош оча, эзе кала, үзе китеп югала. *(Самолет)*

## Җырлар

### *Зөлфия хезмәт сөя*

*Н.Зарипова музыкасы,*
*Г.Таһирова сүзләре.*

Уңган безнең Зөлфия, ялкау түгел, эш сөя.
Җыеп куйган почмагын, киендергән курчагын.
Җыйган урын-җирен дә, куперткән мендәрен дә
Киемнәре эленгән, идәне себерелгән.
Бик ягымлы Зөлфия, нәниләрне бик сөя.
Сеңлесен ул уйната, ә энесен йоклата.

### *Шофер булам*

*Ә. Хәйретдинов музыкасы.,*
*Х.Халиков сүзләре.*

Бакчага барып йөргәнче җәяүләп көн дә,
Әллә шофер булыйм микән, әтием, мин дә?
Алай булса , мә машина, хәзер үк йөрт син...
Рулен борам – машинам ник бер адым китсен.
Рульне әти тоткан иде “Киттек” дип кенә -,
Машина тузан туздырып элдертте генә.
“Кызык булдыңмы?” дип, бәлки, көлеп йөрерсез...
Үсим генә, шофер булам – менә күрерсез!

### *Өйрәтегез генә*

*Ә. Хәйретдинов музыкасы.*
*Х.Халиков сүзләре*

Артист буласы да килә, танкист буласы да килә,
Юл да саласы... Һөнәрләр күп, һөнәрләр күп,
Кайсын гына, кайсын гына сайлап аласы?

*Кушымта:*
Бер эштән дә курыкмыйбыз – өйрәтегез генә.
Гөрләтербез, гөрләтербез, гөрләтербез генә!

Корыч коясы да килә, ГЭСлар корасы да килә,
Йорт та саласы... Һөнәрләр күп, һөнәрләр күп,
Кайсын гына, кайсын гына сайлап аласы?
*Кушымта.*
Тарта сыман төзелеш тә кызык сыман бөтен эш тә -
Кая барасы? Һөнәрләр күп, һөнәрләр күп,
Кайсын гына, кайсын гына сайлап аласы?
*Кушымта.*

### ***Өч кыз***

*Ә. Хәйретдинов музыкасы.,Х.Халиков сүзләре.*

Берсе Дилә, берсе Зилә өченчесе Миңлегөл.
Берсе үлчи, берсе кисә, өчесе дә бик өлгер.
*Кушымта:*
Диләсе дә, Зиләсе дә, Миңлегөл дә ашыга:
Курчакка бит күлмәк кирәк, яулык кирәк башына.
Келтер-келтер машина, машина да ашыга.
Курчакка бит күлмәк кирәк, яулык кирәк башына.
Әле тагын җыелганнар ян тәрәзә каршына.
Алларында келтер-келтер җырлап тора машина.
*Кушымта.*
Тегүче дә булмас бәлки бу кызларның барсы да.
Беркемгә дә артык түгел һөнәрләрнең кайсы да.

### ***Утыр, балам, ашарга...***

*(Халык авыз иҗаты)*

Утыр, балам, ашарга, түгеп-чәчеп ашама,
Матур утыр табында, алдыңа күл ясама
Ипи валчыгыңны койма, аяк астына ташлама.

### ***Беренче рәхмәт***

*Әхмәт Исхак.*

Алсу хәзер зур кыз инде – аңа өч тулган.
Алсу бүген абыйсының яулыгын юган.
Сабынлаган да яулыкны чиләккә тыгып,
Чайкаган да элеп куйган тормыйча сыгып.
Шатлыгыннан нәни Алсуның күзләре яна:
Рәхмәт әйткән моның өчен абыйсы аңа.
Мөмкин түгел шатланмаска: бит шундый рәхәт
Чын күңелдән эшләп алган беренче рәхмәт.

### ***Алмаз***

*Җәүдәт Дәрзаман.*

Бер итеге уңга карый, берсе карый сул якка.
Уңын сулга бутап кигәч, кыендыр ул аякка.
Бияләй ишле-сыңарлы, бүрек каплаган күзен.

Әллә малай, әллә кыз ул, танып та булмый үзен.
Танымаса танымаслар, Алмаз сөенә генә:
Инде бүген икенче көн үзе киенә менә.

***Шофер булам***

*Зәкия Туфайлова.*

Мин дә әтием шикелле, шофер булырга уйлыйм.
Шуның өчен һәрвакыт машинам белән уйныйм.
Тизрәк үсеп шофер булсам, нишләргә белер идем:
Урамдагы бар баланы утыртып йөрер идем.

***Күлмәк тектем***

*Резеда Вәлиева.*

Мин яңа күлмәк тектем, җиңнәрен кыска иттем,
Түгәрәк яка уйдым, ап-ак күбәләк куйдым.
Әнием бик яратты, дәү әнием шаккатты:
-Кызым үсеп җиткән, - ди, күрче, күлмәк теккән! – ди.

***Уку китабы "Иң матур сүз".***

Казан. "Мәгариф" нәшрияты. 2000.

| ***Автор*** | ***Әсәрнең исеме*** | ***Бит*** | ***Яше*** |
|---|---|---|---|
| Татар халык әкияте | Ике ялкау. Ялкау малай | 65, 157 | 5 |
| Абдулла Алиш | Эшче абый. Бал корты һәм Шөпшә. | 71, 162 | 5 -6 |
| Украин халык әкияте | Башак. | 106 | 5 |
| Резеда Вәлиева | Ялкау карга баласы | 110 | 5 |
| Бари Рәхмәт | Аш вакыты | 144 | 5 |
| Габдулла Тукай | Кызыклы шәкерт. | 144 | 5 |
| Ямаш Игәнәй | Зур үстем. Курчагыма кофта бәйлим. Әти кайтыр эштән | 145, 210 | 5-6 |
| Флера Тарханова | Ялт иттерде бүлмәне. | 146 | 5 |
| Мәрзия Фәйзуллина | Теләсәң эш табыла. | 152 | 5 |
| Энҗе Мөэминова | Эш табыла кемгә дә | 212 | 6 |
| Мөнир Мазунов | Безнең бабай | 223 | 6 |
| Ә. Бикчәнтәева | Гөлсем апа | 226 | 6 |
| Фәнис Яруллин | Әнием һөнәре | 225 | 6 |
| Элмира Шәрифуллина | Шофер буласым килә. | 225 | 6 |
| Әзһәр Габиди | Батыр абый. Мин әнигә булышам | 227, 255 | 6 |
| Нур Әхмәдиев | Бәрәңге бакчасында | 243 | 6 |
| Галимҗан Латыйп | Алмалар коела | 244 | 6 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Клара Булатова | Эшләп ашый Әниемнең кызы юк бит. | 245, 255 | 6 |

***Уку китабы “Нәниләргә бүләк”.***
Казан. Татарстан китап нәшрияты. 1988.

| | | | |
|---|---|---|---|
| Габдулла Тукай. | Эшкә өндәү | 23 бит | 4 |
| Идрис Туктаров | Тук-тук! Ялкау өчен ботка суынган | 24, 33 | 6 |
| Фәннүр Сафин | Әткәм эшен яратам | 25 | 5 |
| Абдулла Әхмәт | Ай-һай! | 26 | 5 |
| Зәки Нури. | Без инде хәзер зурлар | 27 | 5 |
| Роберт Миңнуллин | Ипи булса | 27 | 5 |
| Энҗе Мөэминова | Карагызчы!.. | 32 | 6 |
| Җәүдәт Дәрзаман | Тылсымлы чүкеч | 33 | 6 |
| Вахит Монасыйпов | Усал урындык | 35 | 6 |
| Мөнир Мазунов | Кирәк сабын кисәге | 37 | 6 |
| Габделхәй Сабитов | Чүкеч | 45 | 6 |
| Раушания Низамова | Уртак сер | 42 | 6 |

***“Гөлбакча” (балалар бакчалары өчен хрестоматия).***
Казан.Татарстан китап нәшрияты. 1990.

| ***Автор*** | ***Әсәрнең исеме*** | ***Бите*** | ***Яше*** |
|---|---|---|---|
| Газиз Нәбиуллин | Әнигә булышам | 31 | 4 |
| Татар халык әкияте | Ике ялкау. | 51 | 4 |
| Зәкия Туфайлова | Шофер булам | 72 | 5 |
| Резеда Вәлиева | Күлмәк тектем | 72 | 5 |
| Ямаш Игәнәй. | Зур үстем. | 73 | 5 |
| Татар халык әкияте | Тавык, Тычкан һәм Көртлек | 84 | 5 |
| Дамир Гарифуллин | Ял көнне | 143 | 6 |
| Җәүдәт Дәрзаман | Көрәк | 143 | 5 |
| Салават Рәхмәтуллин | Кул арасына кerәм | 143 | 6 |
| Мөнир Мазунов | Кирәк сабын кисәге | 145 | 6 |
| Самат Шакир | Чәчәктән сүз | 155 | 6 |
| Бари Рәхмәт | Аш вакыты | 144 | 6 |

# УЕННАР

**Хезмәткә өйрәткәндә кулланырга тәкъдим ителә**

## *ЭНӘ, ҖЕП, ТӨЕН*

*Хәрәкәтле уен.*
*Биш яшьлек һәм биш яшьтән зуррак балалар өчен.*

Бу уен ачык һавада да, бүлмәдә дә уйнала ала.

Балалар кулга-кул тотынып түгәрәкләнеп басалар. беренче бала – энә, икенчесе – җеп, өченчесе төен булып.

Шул тәртиптә бер саф хасил була. Энә, җеп белән төенне балалар арасыннан төрлечә йөртеп адаштырырга тырыша. Тегеләре бер-берсеннән калмыйча аның артыннан йөриләр. Әгәр берәрсе адашса, аның урынына икенче бала уйный, ә тегесе түгәрәккә баса. Уен шул рәвешчә дәвам итә.

## *ПРОФЕССИЯЛӘР*

*4-6 яшьлек балалар өчен үстерешле уен.*

***Максат:***

Һөнәрләр белән кызыксыну уяту, профессияләрне аера белергә өйрәтү, алар хезмәтенә хөрмәт, шул һөнәр кешесе булып эшлисе килү теләге тәрбияләү.


Өлешләрдән бер бөтенне җыярга өйрәтү - бер предметның кереп торган өлешенә икенче предметның чыгып торган өлешен кертеп беркетү (“Пазлы” уены). Профессияне атап, шул профессиягә туры килгән рәсемне табып, парлап куюларына ирешү, ни өчен шулай кирәк икәнен аңлату.


Сүзлек запасын баету, активлаштыру, сөйләмнәрен үстерү.


Хәтердә калдыру, уйлау сәләтләрен үстерү: логик фикерләргә, игътибарлы булырга өйрәтү.

Бармак мускуллары эшчәнлеген активлаштыру.




12 + 12 =
6 × 3 =
8 : 2 =








## *НӘРСӘ АРТЫК*

*Дидактик уен.*

*4-6 яшьлек балалар өчен.*

***Максат:***

Символиканы аңлый белергә, кайсы һөнәр кешесенә туры килүен билгеләргә өйрәтү, символиканың төп сыйфатларын аңлату: кыска, гомуми, образлы.

Сүзлек запасын баету, активлаштыру, сөйләмнәрен үстерү.

Һөнәрләр белән кызыксыну уяту, алар хезмәтенә хөрмәт, шул һөнәр кешесе булып эшлисе килү теләге тәрбияләү.

Табиб, пешекче, шофер һөнәрләре, бу һөнәр ияләренә нинди эш кораллары кирәк булуы турындагы белемнәрен ныгыту.

Уйлау сәләтләрен үстерү: логик фикерләргә, символика куллана белергә, классларга бүләргә, гомумиләштерергә, хыяллана белергә, игътибарлы булырга өйрәтү.

***Материал:***

Таратма: һәр балага һөнәр кешесенә (пешекче, врач, шофер) туры килгән символ, аңа кирәкле эш кораллары ясалган карточка, (бер эш коралы бу һөнәр иясенә туры килми), бер кызыл квадрат бирелә.

***Уенның барышы:***

Тәрбияче һәр балага өч карточка бирә. Символга карап нинди һөнәр кешесенә туры килүен әйтәләр. Шул һөнәр кешесенә кирәк булмаган эш коралын квадрат белән каплыйлар. Ни өчен шулай эшләүләрен аңлаталар.

Бу уенны шөгыльләрдә дә, аерым гына балалар белән дә, берничә бала белән дә уйнап була.
























## ЯЛ МИНУТЛАРЫ

Шөгыльләр алдыннан һәм барышында, бармак гимнастикасының бик күп төрләрен, әйтемнәр, табышмаклар, күңелле кыска шигырьләр куллану, балаларда шөгыльгә кызыксыну, күңел күтәренкелеге тудыра, куелган максатка ирешү, кызыксындыру чарасы булып тора.

- Безнең бармаклар ялкауланмады: тырышып алар аю ясады.
  Кәгазьне күп тапкыр алар бөкләделәр, әзрәк арып киттеләр.
  Без аларны җиңелчә селкеп алыйк, алга таба эшне дәвам итик.

- Безнең бармаклар, шундый наяннар. Күп нәрсә эшли беләләр алар.
  Матур картина ясар өчен карандаш тота, әвәли дә белә алар.
  Кәгазьне бөкләп кошлар, машиналар, җәнлекләр дә ясыйлар алар.
  Ягез, дусларым, без дә әзерләник, дус тату булыйк һәм эшли башлыйк.

- Без кәбестә турыйбыз, әйбәтләп тоз сибәбез.
  Кишерне дә уабыз, әйбәтләп болгатабыз.
  Суын да чыгарабыз, дару итеп эчәбез

- Җылы суда балыклар
  Йөзәләр һәм чумалар.
  Якынга да киләләр,
  Еракка да китәләр,
  Я комга күмеләләр.

- Кояш арыган - ял итә.
  Кояш чыкты - күтәрелә.
  Кинәт болыт чыкты, җил исте, күк күкрәде
  Яңгыр ява башлады.

- Без ясадык, без ясадык,
  Безнең бармаклар талды.
  Без бераз ял итәбез,
  Тагын ясап китәбез.

- Без инде хәзер зурлар,
  Күп эшли безнең куллар.
  Без идән дә юабыз һәм керләр дә уабыз.
  Тиздән үсеп җитәрбез,
  Шунда эшкә китәрбез.

- Ишектә йозак тора, кем ача, кем ача?
  Боргалаштыргалыйбыз,
  Тагын сузып карыйбыз.
  Ачкыч таптык, йозакны ачтык.

- Кайчы белән кисәләр, кисәләр.
  Аннан баулар ишәләр, ишәләр.
  Мачталарга бәйлиләр.
  Корабльләр киләләр; ту-ту-ту
  (куллар белән бинокльдән карау хәрәкәте ясала)
- Исәнме, ямьле кояш! (Ике кулның да баш бармагын имән бармакка тигерәләр).
  Исәнме, яшел агач! (Ике кулның да баш бармагын урта бармакка тигерәләр).
  Исәнме, җылы җилләр! (Ике кулның да баш бармагын атсыз бармакка тигерәләр).
  Исәнме, якты көннәр! (Ике кулның да баш бармагын чәнти бармакка тигерәләр).
      Яшибез тату бергә,
      Бездән зур сәлам сезгә (учларны йомарлыйлар һәм ачалар)
- (Башта уң кул белән, соңнан сул кул белән уйныйлар).
  Бу бармак урманга китте (имән бармакны күрсәтәләр),
  Бу бармак гөмбә тапты (урта бармакны күрсәтәләр),
  Бу бармак чистартты (атсыз бармакны күрсәтәләр),
  Бу бармак кыздырды (атсыз бармакны күрсәтәләр,
  Бу бармак ашады (баш бармакны күрсәтәләр),
  Шуңа күрә, симерде (баш бармакны өскә күтәрәләр).



*Хуҗалык-көнкүреш хезмәте. Курчак киемнәрен юу*



*Хуҗалык-көнкүреш хезмәте. Уенчыклар юу.*



*Хуҗалык-көнкүреш хезмәте.*
*Шкафларны , киштәләрне җыю, урындыкларны юу.*



*Хуҗалык-көнкүреш хезмәте.*

*Китапларны, уенчыкларны ремонтлау.*



*Табигатьтә эш. Яшелчә бакчасында фасоль утырту.*



*Кул эше. Тукымадан чәчәк ясау.*



***Ашханә буенча дежур тору***

*Балалар алъяпкычлар кияләр, савыт-сабаны, чәнечке, кашыкларны, салфеткаларны өстәлгә куялар. Ел фасылына карап өстәлләрне матурлап бизиләр. Балалар ашаганнан соң буш тәлинкәләрне алып юарга илтәләр.*



***Шөгыльләр буенча дежур тору.***

*Пөхтә итеп шөгыль өчен кирәк булган әсбапларны тараталар.*

*Шөгыль беткәч тиешле урынга җыеп куялар.*



***Табигать почмагында дежур тору.***

*Чәчәкләргә су сибәләр, төпләрен йомшарталар, зур яфраклы гөлләрнең туззаннарын сөртәләр, кечкенә яфраклы гөлләргә су бөркиләр*



***Табигать почмагында эш. Суган утырту.***



***Зурлар хезмәте белән таныштыру.***
*Кер юу бүлмәсендә.*

### *ХЕЗМӘТ ИТҮ ӨЧЕН КИРӘКЛЕ МАТЕРИАЛЛАР, ИНСТРУМЕНТЛАР, ИНВЕНТАРЬЛӘР*

| ***Хезмәт төрләре*** | ***Инструментлар, инвентарьләр*** |
|---|---|
| Үз-үзеңә хезмәт күрсәтү | Өс киеме, аяк киеме өчен щёткалар. Шәхси гигиена әйберләре. |
| Хуҗалык-көнкүреш хезмәте | Тас. Сабын савыты. Чүпрәк. Өстәл, идән, өс аяк киеме өчен щёткалар. Кер, гөлләр юу өчен суда чыланмый торган, төркемдә эшләү, ашханәдә дежур тору өчен чүпрәк алъяпкычлар. |
| Табигатьтәге хезмәт:<br>1.Яшелчә бакчасында хезмәт<br>2.Балалар мәйданчыгындагы хезмәт | Көрәк, лейка, себерке, агач һәм тимер тырмалар, чүп ташу өчен арба, көрәкчекләр, кар ташу өчен чана, кар чистарту өчен агач көрәкләр, җир йомшарткычлар, чиләк, чүпне җыеп алу өчен көрәк, түтәлләрдә утырту өчен үлчәү таяклары, кечкенә таяк көрәкчекләр. |
| Кул хезмәте | Зурлар һәм мәктәпкә хәзерлек төркемнәрендә кул хезмәте өчен аерым почмак булдырыла. Анда эш өстәле, материаллар, иструментлар өчен шкаф, әзер ясалган әйберләрне кую өчен киштә була. Ташландык, табигый материал, кәгазь, картон, поролон, тукыма, кайчы, инә, чигү җепләре, киерге, без, җилем, сәдәпләр кирәк. |
| Табигать почмагында | Лейка. Чиләк. Чүпрәк. Мунчала. Көрәкчекләр. Су |

| | |
|---|---|
| эш | бөркегеч. Суда чыланмый торган алъяпкычлар. |

## КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ


1. Буре Р.С. Учите детей трудиться.
2. Бондаренко А.К. “Дидактические игры в детском саду”. М.,“Просв.”, 1999.
3. Быкова М.В. Уроки трудового обучения.
4. Васильева М.А. Программа воспитания и обучения в детском саду.
5. Гөлбакча (балалар бакчалары өчен хрестоматия). Казан. Татарстан китап нәшрияты. 1990.
6. Г.Бардиер и др. “Я хочу”. Санкт-Петербург, 1993
7. Журнал “Дошкольное воспитание”. № 6, 1995.
8. Зарипова З.М. Белем бирү һәм тәрбия процессында милли төбәк компоненты.
9. К.В.Закирова, Р.А.Борһанова. Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү программасы. Казан. “Хәтер” нәшрияты. 2000.
10. К.В.Закирова. Мәктәпкәчә тәрбия. Казан. 1998.
11. Казыйханов В.С. Тәрбияле бала (җыентык). Казан – 2006.
12. Казыйханов В.С Әхлак дәресләре. Яр Чаллы. 2001.
13. Казыйханов В.С. Иман дәресләре. 1 нче китап. Казан, 2003.
14. Казыйханов В.С. Иман дәресләре. 2 нче китап. “Ихлас” нәшрияты. Түбән Кама, 2005.
15. Казыйханов В.С. Учение о нравственности. Хрестоматия. Наб.Челны. 2000.
16. Казыйханов В.С. Золотой ключ. Издательство “Творчество”. Уфа – 2005.
17. Кокорева Н.Н. Любить труд на родной земле.
18. Лиштван З.В. Конструирование.
19. Л.Венгер. “Угадай, как нас зовут?”. М., “Просвещение”, 1994.
20. Л.В.Русскова. Методические рекомендации к программе воспитания и обучения в детском саду. М.”Просвещение” 1986.
21. Маркова Т.А. Воспитание трудолюбия у дошкольника.
22. М.Ф.Кашапова. Иң татлы тел – туган тел. Казан. “Мәгариф” нәшрияты. 2004.
23. Нечаева В.Г. Воспитание дошкольника в труде.
24. Нурзия. Татар сынлы сәнгате.
25. Нәниләргә бүләк. Казан. Татарстан китап нәшрияты. 1988.
26. Пантелеева Л.В. Художественный труд в детских садах.
27. Рольф Лоберг. “Домашний компьютер”. М., “Издательство “Детская литература”, 1990.
28. Татар халык табышмаклары. Яр Чаллы. “Илел-йорт” нәшрияты. 2000
29. Татар халык мәкальләре. Яр Чаллы. “Илел-йорт” нәшрияты. 2000.
30. Уку китабы “Иң матур сүз”. Казан, “Мәгариф” нәшрияты. 2000.
31. 100 оригами. Г.И.Долженко. Ярославль. 2001.

## ЭЧТӘЛЕГЕ


КЕРЕШ СҮЗ....................... ...................................................................... *1*
1 НЧЕ КЕЧКЕНӘЛӘР ТӨРКЕМЕНДӘ ХЕЗМӘТ ТӘРБИЯСЕ БИРҮ............. *3*
Диагностика, перспектив план, шөгыль конспектлары..
2 НЧЕ КЕЧКЕНӘЛӘР ТӨРКЕМЕНДӘ ХЕЗМӘТ ТӘРБИЯСЕ БИРҮ ............. *6*
Диагностика, перспектив план, шөгыль конспектлары
УРТАНЧЫЛАР ТӨРКЕМЕНДӘ ХЕЗМӘТ ТӘРБИЯСЕ БИРҮ ………......... *13*
Диагностика, перспектив план, шөгыль конспектлары
ЗУРЛАР ТӨРКЕМЕНДӘ ХЕЗМӘТ ТӘРБИЯСЕ БИРҮ.................................. *21*
Диагностика, перспектив планнар, шөгыль конспектлары
МӘКТӘПКӘ ӘЗЕРЛЕК ТӨРКЕМЕНДӘ ХЕЗМӘТ ТӘРБИЯСЕ БИРҮ......... *35*
Диагностика, перспектив планнар, шөгыль конспектлары
МАТУР ӘДӘБИЯТ ӘСӘРЛӘРЕ............................................................. *49*
Хезмәт турында мәкальләр, табышмаклар, җырлар, шигырьләр…................ *49*
Уку китабы “Иң матур сүз”.................................................................. *52*
Уку китабы “Нәниләргә бүләк”.............................................................. *53*
Уку китабы “Гөлбакча”........................................................................ *53*
УЕННАР.................................................................................................. *54*
Хәрәкәтле уен “Энә, җеп, төен”........................................................... *54*
Дидактик уен “Профессияләр”.............................................................. *54*
Дидактик уен “Нәрсә артык?”............................................................... *56*
ЯЛ МИНУТЛАРЫ..................................................................................... *58*
ХЕЗМӘТ ТӨРЛӘРЕ (ФОТОГРАФИЯЛӘР) ............................................. *60*
КУЛЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ...................................................................... *66*

Копирование, переиздание запрещены.
Все авторские права защищены.

Компьютерная верстка, издание.
Тираж 100 экз.
Отпечатано в типографии
Нижнекамский региональный учебно-методический центр
УМЦ
ул. Корабельная, 1, тел.: 41-77-17, т/факс: 41-77-16
www.nizhnekamsk-umc.org.ru e-mail: umc-biz@mail.ru
Лицензия на издательскую деятельность № 06157.